Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 23 (1439) 16 июнь 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

8

Башкортстанда туып-үскән яки күпмедер яшәгән, Бөек Ватан сугышы фронтларында батырлык күрсәткән каһарманнар арасында татарлар бихисап.

14

Советлар Союзы Герое, исеме Казан урамына бирелгән Шамил Рәхмәтуллин һәм аның фамилиядәшләре турында ни беләбез?

24

Мөслимнең балалар сәнгать мәктәбендә киездән җылылык, самимилек бөркелеп торган матур сурәтләр ясыйлар.

Саулык, сихәт җыеп кинәник лә Җәйнең хозурында һәммәбез!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Киләсе уку елыннан башлап Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында татар, рус телләрендә белем бирә торган полилингваль төркем ачыла.
- К.Тинчурин театры Лаеш районы Атабай авылында Татарстанның халык артисты Гата Нуруллинны искә алды.
- Таҗикстанның Дүшәнбе шәһәре янында Сабан туе үтте.
- Уфаның Ә.Вәлиди исемендәге Милли китапханәсендә яшь язучылар һәм шагыйрьләр өчен «Язучы үстерәбез» дигән балалар әдәби студиясе ачылды.
- Апас районында Россия һәм Татарстан рәссамнарының пленэр-симпозиумы узды.
- Курган өлкәсе Эчкен-Йолдыз авылы укучыларына Татарстан хисабына мәктәп формалары тектерәчәкләр.
- Омскиның Халыклар дуслыгы скверында Заманча татар мәдәнияте фестивале узды.
- «Татаркино» Татарстанда төшерелгән 40тан артык фильмны үзенең рәсми сайтына һәм интернет каналына урнаштырды.
- Ю.Платонов исемендәге Саха (Якутия) Республикасы Дәүләт эстрада театры Г. Кариев театрында сукырлар өчен тифлоконцерт тәкъдим итте.
- ТНВ каналында «Башваткыч», «Әдәби хәзинә» тапшырулары редакторы, Татарстанның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре Әлфирә Мәһдиева 56 яшендә вафат булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Илгиз ЗӘЙНИЕВ, драматург, режиссер:

«Ярышка чыгасың, бәйгегә барасың икән, җиңәргә дә, җиңелергә дә әзер булып барырга тиешсең. Җиңеләсең килмәсә яки хөкемдарлар ошамаса – катнашма! Шул гына! Җиңелүне дә ничек бар – шулай кабул итәргә кирәк! Димәк, вакыты җитмәгән».

СЫНАМЫШЛАР

16 июньдә җил көньяктан иссә, сабан ашлыклары уңа, төньяк-көнбатыштан иссә, җәй яңгырлы була ● 18 июньдә җылы һәм аяз булса, бодай һәм арыш бөртекләре эре була ● 21 июньдә чык мул төшсә, киндер һәм җитен уңа ● Гадәттә, 22 июньдә каен җиләге өлгерә ● Кичтән томан төшсә, көн аяза һәм җылыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **2 сәгать 59 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 31 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 32 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **2 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **23 июньдә 17 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

17 июнь – тарих фәннәре кандидаты, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Шамил Фатих улы Мөхәммәдьяровның тууына 100 ел (1923–2005);

– шагыйрь һәм хикәяче Ринат Гыймазетдин улы Батталовның тууына 75 ел (1948-2018).

19 июнь – график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эмиль Гариф улы Ситдыйковның тууына 100 ел (1923–1987).

20 июнь – рәссам Илдус Миңнулла улы Насретдиновның тууына 90 ел (1933-2016).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 18-20 июнь.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(18-26 июнь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 27 нче көне

УКЫ ДА УЙЛА!

СЕБЕР ҖЫРЛАРЫ, *яки* Ахмакларга җавап йөзеннән...

«Җырын алалмадым – серен алалмадым». Себер татарлары тормышлары һәм эчке дөньялары җыр-көйләр белән тыгыз бәйләнгән булуын әнә шундый тапкыр сүз белән белдергән. Бу гыйбарәне фольклорчы галимнәребез Илгиз Кадыйров һәм Илсөяр Закированың Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында басылып чыккан «Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты (Себер ареалы)» китабында очраттык. Себер татарларының музыкаль мирасын өйрәнүгә багышланган шәлкемнән икенче бу китапта 1968-1972 елларда үткәрелгән фәнни экспедицияләр вакытында татар музыкасы һәм фольклор белгече И.Кадыйров тарафыннан тупланган дастан, бәет, мөнәҗәтләрнең ноталары һәм текст үрнәкләре тәкъдим ителә. Себернең Төмән, Новосибирск, Томск, Омск, Кемерово өлкәләрендәге 13 районда 49 авыл кешеләреннән язып алынган җырлар, бәетләр тупланган. Ни кызганыч, бүген аларның күбесе онытылган. Бер китапта халыкка никадәр байлык кире әйләнеп кайта! Җырны тикмәгә генә сергә тиңләмәгәннәр. Бүген Себер татарларын аерым халык итеп бүлеп чыгарырга көчәнүчеләргә бик шәп җавап бар бу китапта. Теге яки бу халыкның килеп чыгышы турында фикер йөртү өчен, телен генә түгел, җыр-музыкасын, гамәли-бизәү сәнгатен, гадәт-йолаларын һәрьяклап өйрәнү кирәк, дияргә теләгән авторлар. Халыкның җаны, сере шунда.

И.Кадыйров Себер татарларының шигъри музыкаль иҗаты формалашуын дүрт чорга бүлә. Иң борынгысын гомумтөрки чор дип беләбез. XVII гасырда Идел буеннан татарлар күчеп килү белән башланган яңа чорда исә төрле сәбәпләр аркасында күп гасырлар аерылып яшәгән һәм үз музыкаль фольклорын тудырып өлгергән этник төркемнәр бер-берсенә яңадан якыная башлый. Экспедиция материаллары Себер төбәгендә татар музыкаль фольклорының тулы яңгыраш алуын һәм барлык жанрларның да диярлек иҗади файдаланылуын күрсәтте, ди автор. Мондый тыгыз һәм нәтиҗәле иҗади бәйләнеш музыкаль һәм шигъри фикерләүдә уртак сыйфатлар булганда гына мөмкин, дигән нәтиҗә чыгара ул. Чыннан да, күп кенә йола көйләүләре, әйтик, «Яңгыр теләү», Себер татарларыныкы гына булмыйча, гомумтатар фольклорының иң борынгы үрнәкләреннән түгелмени?! Себер татарларыннан күпләп язып алынган «Бүз егет», «Кузы-Көрпәч һәм Баян-Сылу», «Таһир-Зөһрә», «Сәйфелмөлек» дастаннары, «Сак-Сок» бәете Идел буе һәм Себердә яшәүче милләттәшләребезнең бер ярудагы Сак белән Сок кебек кавыша алмыйча тилмереп яшәгән балалары икәнен дәлилләмимени?!

Гомумән, кайсы гына җырны алма, ике этник төркем арасында охшашлыкка тап буласың. Әнә, кәләшне туган-үскән өеннән озатканда, чәчләрен элеккечә бер урынына ике толымга аерып үрә-үрә җырлана торган «Яр-яр» җырын гына алыйк. И.Кадыйров бу җырның М.Фәйзинең «Кызыл йолдыз» пьесасында да очравын искәрткән. Драматург аны халык авыз иҗатыннан алган, билгеле. Идел буенда кыз озатканда «Яр-яр» җыры башкарылган дигән сүз бу. «Хан кызы» да Себер татарларында гына таралган җыр түгел. Автор, мәсәлән, аның олуг шагыйребез Г.Тукайның җырлар дәфтәрендә дә булуы турында искәрткән. Новосибирск өлкәсе Чаны районы Белекте авылыннан Шәмсенур апа Йосыпова «Тамчы тама» җырының бабайлар заманыннан билгеле булуы турында әйтсә дә, аның көе С.Габәши һәм Г.Әлмөхәммәдовның беренче татар операсы «Эшче»дәге Нигъмәт ариясенә туры килә икән.

Дөрес, Себер татарларында дастан, әкиятләрне йомак, җырулы йомак дип йөртәләр. Җырулы йомакта көйле өлешләр бар. Әмма исеме башка булса да, әкият барыбер әкият булып кала, һәм аларны көйләп сөйләү бер ерак милләттәшләребезгә генә хас нәрсә түгел. Проза һәм шигъри юлларның чиратлашып килүе элек татар әкиятләренең көйләп сөйләнгәненә бер дәлил булып тора, дигән И.Кадыйров.

Бүтәннәргә чокыр казыма, үзең шунда төшәрсең, дигән кебек, халыкларны бер-берсенә өстерүчеләр үзләре бер көнне ыштансыз калмагае. И.Кадыйров «Сак-Сок» бәетенең «Хазбулат удалой» көенә җырланган төрләрен байтак очраткан. Бу күренеш Көнбатыш Себергә генә хас түгел, Свердловск өлкәсендә дә шундый ук көйгә башкарылган бәетне ишетергә туры килгән. «Халык җәүһәрләре» китабында композитор Җәүдәт Фәйзи дә бу рус җырының бәет көе буларак киң таралганы турында язганда, Оренбург татарларын мисал итеп китергән. Ары китеп ул «Сак-Сок»ны «Яблочки» көенә башкарганнарын да ишеткәне турында язган һәм, болар татар җырлары түгелме икән, дип сорау куйган. Үзе Оренбургта туган, татар җырларын җыючы, эшкәртүгә зур өлеш керткән олы композитор буш сүз сөйләмәс, шәт... «Сак-Сок» бәете генә түгел, Омск өлкәсенең Усть-Ишим районында «Яр-яр» туй җыры да «Хазбулат» көенә башкарыла икән. Борынгыдан килгән йола җырларының бүтән кавемнәрнең көенә җырлануы юк дәрәҗәсендә сирәк, ди белгечләр... 1905 елгы революциягә багышланган «Икенче садә» татар революция җырының нигезендә шулай ук берникадәр үзгәртелгән «Хазбулат» җыры ята, ди.

Себердә яратып җырланган «Габидулла бәете» дә кызыклы. Аның бериш юллары Пугачев фетнәсенә кагылышлы документлар арасында очрый. Шуннан чыгып, Габидулла Казан тирәсендә яшәп, Пугачев явында катнашканы өчен сөргенгә сөрелгән кеше, дип нәтиҗә чыгарырга мөмкин. Бараба татарларыннан язып алынган «Елашмагыз, туганнар!» бәетенең Идел буе татар-мишәрләренең җыры икәне ачыклана. Көчләп чукындыру турында зар елап җырлана торган «Керәшен җыры»н да табалар Себердә. Ә бит башкортлардан кала бәетләр бүтән бер төрки халыкта да юк. Башкортлар исә, бәет жанры безгә татар мәдәниятеннән кергән, дип сөйли. Татар бәетләре Себер җирлегендә берегеп яшәп киткән икән, Себердәге милләттәшләребезне бүтән халык дип ялган сөйләүләргә ничек тел әйләнсен?!

Себер татарларында мөнәҗәт жанрының таралуы, аерым алганда, «Бакырган», «Мөхәммәдия», «Бәдавам» китапларыннан өзекләрне бүген дә күзләрен яшьләндереп җырлаулары шулай ук Себер татарларының зур татар дөньясыннан үзенчәлекле кыйпылчыгы булуына бернинди шик калдырмый.

Җырларга килгәндә дә шул ук хәл. Себердәге милләттәшләребездән язып алынган «Башмагым», А.Ключаревның «Татар халык көйләре» китабында «Әхмәт солдат җыры» буларак теркәлгән «Шәкүр» җыры, күпләгән «Солдат җырлары», мәшһүр «Су буйлап» җырын хәтерләткән «Бандит көе», «Баламишкин» һ.б. Себер ареалын татар тарихыннан аерырга омтылучыларны ахмакка чыгара.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Юраган юш килә

Мәгълүм булганча, киләчәкне фараз итү бик хуп гамәлләрдән саналмый. Чөнки кылган фаразларың дөрес булып чыкмаска да мөмкин. Икенче яктан, үз киләчәгенә битараф калып та яшәп булмый: чөнки алдагысын да кайгырту өчен кешегә акыл бирелгән. Димәк, бөтен хикмәт – фаразларны мөмкин кадәр дөрес итеп, күпьяклы вә тирән анализ нәтиҗәләренә таянып нигезли алу сәләтендә. Ә зур сәясәттә киләчәкне дөрес гөман кылу сәләте бик сирәкләргә генә бирелә, һәм шуңа күрә андый һәвәслек геосәяси даирәләрдә инде аеруча югары бәяләнә. Шул ук вакытта һәр чорның үзенә генә хас үзгәлеге дә иртәгесе көнгә үз корректурасын кертә. Ә глобаль кризис вә әхлаксызлыктан дөньяның асты өскә килгән бүгенге шартларда «геосәяси күрәзәчелек» талантының әһәмияте инде тагы да арта төшә. Моны истә тотып, сәхифәбездә бу юлы инде узган гасырның дөньякүләм танылган шундый аналитикларыннан икесе – Збигнев Бжезинский (1928-2017) һәм Генри Киссинджер (быел ул 27 майда инде үзенең 100 яшьлек юбилеен бәйрәм итте) шәхесләренә кыскача тукталырбыз.

Алар икесе дә – бер чор, бер үк даирә һәм хәтта бер үк кавем кешеләре. З.Бжезинский - социолог һәм дәүләт эшлеклесе, 1977-1981 елларда АКШның 39 нчы президенты Джимми Картерның милли иминлек буенча киңәшчесе булып торган. Ул – Өчьяклы комиссияне оештыручыларның берсе һәм аның директоры (1973-1976) да. З.Бжезинскийның хезмәт юлы шактый ук бай һәм гыйбрәтле дә. Озак еллар дәвамында ул АКШ тышкы сәясәтенең әйдәп баручы идеологларыннан берсе һәм АКШ хөкүмәтенең консультанты булып кала, Джонс Хопкинс университеты каршында эшләп килгән Стратегик вә халыкара тикшеренүләр үзәге хезмәткәре, шулай ук Алдынгы халыкара тикшеренүләр мәктәбе профессоры булып та эшли, җитди хезмәтләр авторы булып тора. Советлар Берлегенең таркалачагы турында Бжезинский әле 1970 елда ук әйтә. Моның сәбәбен ул бу илнең эчке каршылыкларга таянып корылуы, шуңа аның таркалуы бары тик вакыт мәсьәләсе генә булып калуы белән аңлата. Ә үзенең 1997 елда (моннан 26 ел элек!) дөнья күргән «Зур шахмат тактасы: Америка хакимлеге һәм аның геостратегик императивлары» дигән зур хезмәтендә ул АКШ өчен иң зур потенциаль куркыныч Кытай, Россия һәм Иран оештырган альянс ягыннан булачагы турында яза, моның сәбәбен аларның уртак идеология нигезендә түгел, ә Штатлар сәясәте белән килешмәүләре нәтиҗәсендә, аңа каршы оешулары белән нигезли. Бүген исә, чыннан да, Россия һәм Кытай үзара тыгыз сәяси, икътисади һәм хәрби элемтәләр кора. Ә Кытай һәм Иран гомумколачлы хезмәттәшлек турында 25 елга исәпләнгән килешү төзеде. 2012 елда Бжезинский АКШның көчсезләнүе дөньяның тотрыксызлануына китерәчәге, дөнья лидеры булып отыры Кытайның күтәрелү мөмкинлеге турында да искәртә. Шул ук вакытта ул 2014 елда Украинада башланган сәяси кризис Россиядәге тотрыксызлыкка китерәчәге турында да кисәтеп калдыра.

Инде «геосәяси юраучы»ларның икенчесе – Г.Киссинджерга күчик. Ул да – АКШның дәүләт эшлеклесе, АКШ президентының милли иминлек буенча киңәшчесе (1969-1975) һәм бу илнең дәүләт секретаре (1973-1977) дә булып торган, дипломат вә халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эксперт, Тынычлык буенча Нобель бүләге лауреаты (1973). Киссинджер АКШ белән СССР арасында киеренкелекне йомшарту сәясәте инициаторы, шулай ук АКШ-Кытай мөнәсәбәтләрен башлаучылардан да санала. Шул ук вакытта аның исеме белән АКШ ның Кампучияне бомбага тотуын, Чилидәге хәрби түнтәрелешне, Аргентинадагы сугышны һәм Бангладеш бәйсезлеге өчен сугышта АКШның Пакьстан ягында булуын да бәйлиләр. Әмма, Бжезинскийдан аермалы буларак, Киссинджер инде күптәннән Кремльдә дә – көтеп алынган кунак һәм консультант. Ул Россия Тышкы эшләр министрлыгының Дипломатик академиясе докторы да санала икән. Шуңа бу шәхес геосәясәттә бүген дә зур бәхәсләр тудыра, күпләр аның «Тынычлык докторымы», әллә «Явызлык докторымы» икәнлеген ачыкларга тырыша.

Хәлбуки, Киссинджерның бүгенге вакыйгаларга карата да үзгә фикере бар һәм алар, ни гаҗәп, гел үзгәрә тора. Ул инде Америкага Кытай мәнфәгатьләрен дә танырга туры киләчәк дип саный, шуңа якларны сабырлыкка чакыра. Кытай белән Россиянең табигый союздашлар булмавын да таный. Шуңа күрә АКШ һәм Кытайга үзләренең хәрби егәрен бүгенге дөньяда тыю факторы итеп кулланырга киңәш итә. Ә яңа дөньяви тәртип турында Киссинджер: «Без барыбыз да яңа дөньяда яшәвебезне танырга тиеш, чөнки бөтен эшләгәнебез башка юлдан да китәргә мөмкин. Гарантияле юнәлеш юк», – дип әйтә. Бу аның геосәясәт кризисын тануын да аңлата. Ә киләчәкне ул Иммануил Кант фикеренә сыенып юраудан ары китми: тынычлык йә кешенең дөньяга иминлек кирәклеген төшенүе, йә нинди дә булса һәлакәт аша киләчәк. Соңгысын кешелек дөньясы инде глобаль дәрәҗәдә дә кичерә. Ә нәрсәнедер ул һаман да аңлап бетерә алмый. Нәрсә икән ул?

Фоат УРАЗАЙ.

Казанның милли бәйгеләре

Казан мэриясе 15 июльгә кадәр рәссамнардан «Саумы, Казан!» бәйгесенә гаризалар кабул итә. Гаризалар дөньяның теләсә кайсы урынында яшәүче 18 яшьтән өлкәнрәк авторлардан кабул ителә. Иң мөһиме, рәсемдә Казан сурәтләнгән булсын. Жюри эшләрне ике яшь категориясендә – 35 яшькә кадәр һәм 35 яшьтән өлкәнрәк, ике юнәлеш буенча – рәсем сәнгате һәм графика буенча бәяләячәк. Җиңүчеләр беренче урын өчен – 120 мең сум, икенче урын өчен – 100 мең сум, өченче урын өчен – 80 мең сум күләмендә акчалата бүләк алачак. Бу хакта «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында мэриянең милли проектларына багышланган матбугат очрашуында сөйләделәр.

Казан шәһәре башкарма комитетының тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе Айсылу Лерон бәйге нәтиҗәләре буенча 12 җиңүче – өч урынга дүртәр кеше чыгачагын әйтте. Җиңүчеләрнең эшләре шәһәр көненә багышланган күргәзмәдә тәкъдим ителәчәк.

Бәйгедә катнашу өчен гаризаларны 15 июльгә кадәр saumykazan@mail.ru электрон адресына юлларга кирәк.

«Саумы, Казан!» бәйгесе беренче тапкыр 2021 елда үткәрелгән. Ул вакытта әдәби әсәрләр кабул ителгән. Быел Казан хакимияте рәссамнарга игътибар бирергә булган.

«Үз телем» бәйгесендә иң яхшы дип табылган идея авторларына проектларын тормышка ашыру өчен грантлар тапшырылачак. Бәйгенең гомуми приз фонды – ике миллион сум. Айсылу Лерон әйтүенчә, бәйгедә җиңүченең бүләге төгәл билгеләнмәгән. Акча, проектның чыгымнарына карап, приз фондыннан бүленә. Мәсәлән, татар мәдәниятен үстерүгә багышланган проектка 200 мең сум кирәк икән, шул сумма бирелә. Тәкъдим ителә торган эшнең сметасы һәм аны тормышка ашыру юллары күрсәтелгән булырга тиеш.

Ике ел эчендә Казанда популярлык казанган «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты быел җәйнең һәр пәнҗешәмбесендә Камал театры янында узачак. Яңа сезонга 15 июньдә старт бирелде.

«Без моңарчы «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектын шәһәрнең төрле паркларында һәм скверларында үткәрә идек. Быел аңа яңалык керттек. «Хәрәкәттә – бәрәкәт» бер генә нокта – Камал театры янында узачак», – диде Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Гүзәл Сәгыйтова.

Ул Казан халкын һәм шәһәр кунакларын татар бию хәрәкәтләрен өйрәнергә чакырды. Аның сүзләренчә, чаралар татар телендә барачак.

Болгарда татар аланы

Бу атнада X Төбәкара «Болгар – Туган тел» форумы башланды. Ул «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча» республика программасын тормышка ашыру кысаларында Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә оештырыла. Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова республика күләмендә балаларның үсеше өчен яхшы шартлар булдырылуына игътибар юнәлтте. «Сез милләтебезне өйрәнер өчен Болгар җирлегенә килгәнсез. Ә биредә бит күпме кеше омтыла! Аларның һәркайсының хыялы чынга ашсын иде», – диде ул.

«Яңарыш» Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу республика фондының башкарма директоры Зөлфия Сөнгатуллина бирегә 11 төбәктән балалар килүен әйтте.

Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте» Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең республика бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләйманов беренче тапкыр «Сәләт»кә 1998 елда Чистайга барганын искә алды. «Беркайчан да ул мизгелләрне онытмам. Анда танышкан дусларым белән без әле дә бергә. Мәсәлән, Гүзәл Усманова белән без «Сәләт»тә танышып, бүген бергә проектлар оештырабыз. Анда булган хисләр, энергия мине әле дә әйдәп бара», – диде ул.

Ралинә СӘЛИМОВА.

«Микулай» зур юлга чыкты

«Микулай» фильмын Россиянең 109 кинотеатры күрсәтергә алынган. Фильм прокатка чыгачак 22 июньгә кадәр ул сан артырга мөмкин.

«Прокатчы «Кино.Арт.Про» кинокомпаниясе фильмның зур потенциалын күрде. Мәскәүдә генә дә 21 кинотеатрда күрсәтеләчәк. Санкт-Петербург, Калининград, Төмән, Новосибирск, Казан... Исемлек тагын да артырга мөмкин», – диде «Микулай» фильмының прокаты уңаеннан оештырылган матбугат конференциясендә кинорежиссер Илшат Рәхимбай.

«Бу чын психологик триллер, милли мәдәният ягыннан караганда, андый киноның әле булганы юк иде. Бу күп катламлы фильм. Фон булып Питрәч районының Сарсаз авылы тора. Миңа калса, Татарстан кешесе бу киноны карарга тиеш», – диде Татарстан Мәдәният министрлыгының бүлек мөдире, тарихчы Айрат Фәйзрахманов. «Без бу фильмны Татарстан киноиндустриясе өчен уникаль тәҗрибә дип саныйбыз. Ул – Илшат Рәхимбайның Россия югарылыгындагы, ә бәлки халыкара аренада зур дебюты. Әлеге фильмны Татарстанда керәшен мәдәнияте, уникаль образлар турында сөйли торган әсәр дип тә кабул итәбез», – дип дәвам итте ул.

Фильмда төп рольләрнең берсен – Меркум исемле картны уйнаган Татарстанның халык артисты Рафик Таһиров «Микулай» әсәренең дөньяви материал булуын ассызыклады.

Илшат Рәхимбай «Микулай» фильмын төшергәндә ярдәм иткән кешеләргә рәхмәтен җиткерде. «Татарстанда калкый башлаган кешене батыралар, диләр. Мин кино төшергәндә андый хәлнең киресен тойдым. Кешеләр безгә ышанды, һәм без дә кешеләргә ышандык», – диде ул. «Мин күптән инде фильмны үземнеке генә дип санамыйм. «Безнең фильм» дим, чөнки аның эшендә күп кеше катнашты һәм әле дә катнашучылар арта бара. Авыр вакытларда краудфандинг оештырдык, без үтәргә тиешле авыр юлны үткәндә бөтен Татарстан булышты. Фильм бик күпләр ярдәмендә эшләнде», – диде Илшат Рәхимбай.

1 нче биттә – Казанның «Ливадия-Татарстан» шифаханәсендә узган «Россия көче» спорт марафоны кысаларындагы күмәк гимнастика күренеше. Фото: gossov.tatarstan.ru

Мәгариф министрлары җыены

Казанда узган мәгариф министрларының «Киләчәкне формалаштыру» халыкара форумына 31 дустанә ил делегациясе килде. Чарада барлыгы 101 чит илдән вәкил катнашты. Алар арасында Мисыр, Катар, Бразилия, Оман, Сенегал, Мали, Зимбабве, Үзәк Африка Республикасы, Сүрия Гарәп Республикасы, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Пакьстан, Мьянма, Куба, Венесуэла, Беларусь, Әрмәнстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан, Казахстан һ.б. бар.

Эшлекле программа барышында катнашучылар икътисадны үстерүдә мәгарифнең роле, сыйфатлы белем бирүнең уңайлылыгы, яшьләр белән эшләү, балалар ялы, физик мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү, башка илләрдә рус телен укыту турында фикер алышты. Алар үзләренең уңышлары белән уртаклашты, ике яклы хезмәттәшлекне җайга салу мәсьәләләрен тикшерде, Россиянең алдынгы мәгариф технологияләрен бәяләп, илебезнең мәдәни мирасы белән танышты. Форумда фикер алышулар барышында чит ил укучыларын олимпиадаларга әзерләргә, чит илләрдә БДИ кертергә һәм рус телен өйрәтү өчен укытучыларны дустанә илләргә күбрәк җибәрергә тәкъдим иттеләр.

Пленар утырышның модераторы Россия мәгариф министры Сергей Кравцов булды. Президиумга Россия Президенты ярдәмчесе Андрей Фурсенкодан тыш шулай ук РФ фән һәм югары белем министры Валерий Фальков һәм ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевне чакырдылар. «Үз вакытында совет мәгариф системасы дөньяда иң яхшыларның берсе дип таныла. Мәгарифнең совет системасында, бигрәк тә табигый-фәнни мәктәптә, инженер белемендә сакланып калган традицияләрен бүген үстерәбез, һәм бу Россияне дөньяда, шул исәптән халыкара тикшеренүләрдә һәм олимпиадаларда, иң яхшы нәтиҗәләргә китерә», – дип билгеләде Кравцов.

Мәгариф министрлыгы шулай ук «Россия укытучысы чит илдә» проектын киңәйтергә һәм укытучыларны кызыксынган илләргә җибәрергә тәкъдим итте. 2023/2024 уку елында ук проекта Китай, Венесуэла, Куба һәм Мисыр мәктәпләре дә кушылачак.

В.Фальков үз чыгышында фән һәм югары белем бирү өлкәсендә башка дәүләтләр белән хезмәттәшлек темасына кагылды.

А.Фурсенко әйтүенчә, кайбер илләр үзләренең мәгариф системасындагы мәсьәләләрне хәл итәсе урынга читтәге белгечләрне үзләренә җәлеп итү белән шөгыльләнә. «Минем уйлавымча, безнең төп бурыч – яхшы мәгариф системасын һәм сәнгатьтәге, төрле өлкәләрдәге коллегаларыбыз белән бергә кызыклы эш урыннары булдыру», – дип билгеләп үтте ул.

Татарстанның мәгариф өлкәсендәге уңышлары белән республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов уртаклашты. Ул хәбәр иткәнчә, Татарстан югары уку йортларында 21 мең чит ил гражданы укый. Иң күп чит ил студентлары – Урта һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия, Якын Көнчыгыш илләреннән. Моннан тыш, Үзәк Азия төбәге дәүләтләре белән хезмәттәшлек итүдә Татарстан алдынгы урыннарны били, дип өстәде Р.Миңнеханов.

Тел өчен җан аткан галим китабы

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында татар телендә белем бирү эшен актив оештыручыларның берсе булган галим, техник фәннәр кандидаты, 1977-2021 елларда институтның механика кафедрасы доценты Рәшит Шакирҗановның үзе исән чагында язылган китабы тәкъдим ителде.

Бу монография Рәшит Шакирҗановның 30 ел эчендә (1990-2020 елларда) татар телендә югары белем бирү өлкәсендә тупланган тәҗрибәсен анализлау һәм киләчәк буыннарга тапшыру максаты белән язылган.

Китап «Туган телне саклау юлында» дип атала. Аның дүрт кисәге автор шөгыльләнгән дүрт өлкәгә карый: татар теле, механика, милли мәгариф һәм журналистика. 5 нче кисәге авторның тормыш юлына багышланган.

Китапны механика кафедрасы доценты Фәрит Шакирҗанов тәкъдим итте. Китап презентациясендә КДАТУ ректоры Рәшит Низамов һәм белем бирү эшчәнлеге буенча проректор Илфак Вилданов, төрле кафедраларның татарча укытуда катнашкан укытучылары, физика-математика фәннәре кандидаты Марат Лотфуллин һ.б. катнашты.

Сугыш кичкән ат

Башкортстанның Миякә районы Илчегол авылында Керчь кушаматлы легендар атка һәйкәл ачылды.

Ул – Бөек Ватан сугышыннан туган ягына әйләнеп кайткан бердәнбер ат. Һәйкәл җирле инициативаларга ярдәм күрсәтү программасы кысаларында хакимият ярдәмендә торгызылган.

Керчьне 1942 елда фронтка җибәрәләр. Ул 112нче Башкорт кавалерия дивизиясе составында Уралдан Берлинга кадәр озын юл уза, ике тапкыр яралана. Сугыш беткәч, Семен Буденныйның шәхси боерыгы белән атны туган ягына кайтаралар, ул күмәк хуҗалыкта эшләвен дәвам итә, район Сабан туйларының мактаулы кунагы була.

● Миякә районы хакимиятенең матбугат хезмәте фотосы.

Сабан туе – дуслык бәйрәме

Әлмәттә Сабан туе кунакларын һәм катнашучыларны республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагуманов һәм «Татнефть» ААҖ генераль директоры Наил Мәганов белән парламент рәисе җирле үзешчән коллективларның концерт мәйданчыкларында, халык осталары һәм һөнәрчеләре эшләнмәләре күргәзмәләрендә булды.

Дәүләт Советы Рәисе Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановның котлавын ирештерде. «Сабан туе төрле милләт һәм дин вәкилләренең очрашу урыны булды һәм булып кала, халыклар арасында дуслык һәм үзара аңлашуның аерым атмосферасын тудыра, – дип билгеләп үтә республика башлыгы анда. – Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елында бәйрәм республикада этномәдәни күптөрлелекне саклауга һәм үстерүгә ярдәм итә».

Ф.Мөхәммәтшин әйтүенчә, Әлмәт Сабан туеның үзенчәлекле төсмерләре бар, бу матур аланда төрле милләтләрдән меңләгән кеше җыела. «Бу көнне без алдынгы авыл хуҗалыгы хезмәткәрләрен – агрономнар һәм терлекчеләрне, фермерлар һәм хуҗалык башлыкларын, механизаторлар һәм инженерларны хөрмәтлибез», – дип басым ясады парламент башлыгы. Район һәм авыл җирлекләре җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, парламент җитәкчесе аларны авылның киләчәге турында һәрвакыт кайгыртырга өндәде. «Авылларны саклагыз, һәр хуҗалыкны, – диде Ф.Мөхәммәтшин. – Нәкъ менә авыл республикабызның барлык халыкларының күп гасырлык традицияләрен, яшәү рәвешен, туган телен, мәдәниятен, милли киемнәрен саклаучы булып тора. Ә рус, татар, чуаш, мордваларның һәм башка халыкларның дус-тату яшәве безнең төп байлыкларыбызның берсе булды һәм шулай булып кала да!»

● Хәзер Җирдә 8,09 миллиард кеше яши, халык саны елына 90 миллион кешегә арта бара. Планета халкының 70 проценттан артыгы дөньяның 20 илендә яши, Кытай белән Һиндстанда 1 әр миллиардтан артыграк кеше гомер сөрә. 15 яшьтән өлкәнрәк 4 894 412 455 кеше укый-яза белә (бу планета халкының 86 процентын тәшкил итә), ә 777 070 761 кеше – грамотасыз.

● Халыкара валюта фонды һәм Бөтендөнья банкы исәпләве буенча, җиһанда иң күп саф акча һәм алтын резервлары запасы Кытай Халык Республикасында – барлыгы 3,43 триллион долларлык. Бу икенче урындагы Япониядәгедән (андагы запас 1,41 триллион долларлык) ике тапкырга диярлек күбрәк. Аннары исемлектә Швейцария (1,11 трлн $), АКШ (0,72 трлн $), Һиндстан (0,64 трлн $) һәм Россия (0,63 трлн $) килә (әмма бу хәзерге вакытта арест салынган 300 миллиард долларны кушып исәпләгәндә генә – аларны санамасаң, РФ исемлектә икенче дистәгә күчә).

Хөсәен Фәезханов фидакярлеге

Татар җәмәгатьчелеге күренекле тарихчы-галим, теолог һәм көнчыгыш белгече Хөсәен Фәезхановның тууына 200 ел тулуны билгеләп үтте. Шушы уңайдан Казанда «Россия – Ислам дөньясы» XIV Халыкара форумы кысаларында «Х.Фәезханов һәм Ш.Мәрҗани – бөек галимнәр, дин белгечләре һәм мәгърифәтчеләр» дип исемләнгән VIII Россиякүләм фәнни-гамәли конференция һәм КФУның Тарих музеенда «Хөсәен Фәезханов. Хакыйкатькә тугрылык» дип аталган күргәзмә ачылган иде. Без шушы чаралар вакытында Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Дамир Мөхетдинов белән әңгәмә дә кордык. Ул менә ниләр сөйләде.

Х.Фәезханов Түбән Новгорд өлкәсендә урнашкан Сафаҗай авылында дөньяга килә. Бу – халкыбызга морзалары, имамнары, ишаннары, хәзрәтләре белән танылган авыл. Сафаҗайда башлангыч белемне алган Х.Фәезханов 1850 елларда Казан тарафына кузгала, Бәрәскә, Апанай, Иске таш мәчет мәдрәсәләрендә укый. Аннары Мәрҗани мәдрәсәсендә, Шиһабетдин хәзрәт Бохарадан, Сәмәркандтан кайткан вакытта, аңардан дүрт ел дәвамында, беренче шәкертләрдән булып, дәресләр ала, аның атаклы бер укучысы булып китә. Х.Фәезханов мәдрәсәләрдә укыган вакытта ук үзлегеннән рус, гарәп, фарсы, төрек телләрен, тарихын һәм әдәбиятын өйрәнә. Ул хәтта шул ук елларда университетка А.Казем-Бек һәм И.Березин лекцияләренә йөри, галимнәр белән аралаша, фән казанышлары белән якыннан таныша, фәнни-тикшеренү алымнарын үзләштерә. Ш.Мәрҗанинең иң күркәм кульязмасы «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел әсляф» дигән әсәрендә Х.Фәезхановка багышланган аерым бүлек тә бар. «Ш.Мәрҗани хәзрәтләре Х.Фәезхановның талантлы кеше булганлыгын күрә. Үзенең галим буларак аңардан бик файдалануын да искәртә, аны шулкадәр яратып, олуг күреп, аңа карата хезмәтләр дә калдырган», – ди Д.Мөхетдинов.

Мәдрәсәне тәмамлаган вакытта Фәезханов алдында ике юл ачыла. Ул йә Бохарага барып белемен киңәйтү юлыннан китәргә, яисә бу якларда калырга тиеш була. Ш.Мәрҗани Хөсәеннең Бохарага барып гомерен дини белемнәргә багышлавын тели. 1855 елда Казан император университетының Көнчыгыш бүлеге Санкт-Петербургка күчерелгәннән соң, А.Казем-Бек һәм И.Березин тәкъдиме белән, Х.Фәезханов шул уку йортына төрек-татар теле укытучысы итеп чакырыла. Петербург укыту округы попечителенең бу уңай белән мәгариф министрына юллаган тәкъдим язмасында, «Бу чын ориенталистны... төрек телләре кафедрасына алу файдалы булыр иде», диелә. Ләкин рәсми карар тоткарланып тора. Х.Фәезханов, фәнгә үз өлешен кертергә омтылып, хезмәт хакы алмыйча эшләргә ризалаша, тик «үзенең университетта башкарган эшен чын хезмәт итеп санауларын» шарт итә. Петербург университеты җитәкчелеге министрлыкка яңадан тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгать белән чыга. Мәгариф министры 1857 ел ахырында гына Х.Фәезхановны Петербург университетының төрек-татар телләре укытучысы итеп билгеләргә рәсми рөхсәт бирә. Биш елдан соң, 1862 елда, ул, сенат указы белән, Көнчыгыш телләре факультетының лекторы итеп билгеләнә, Казан һәм Санкт-Петербург университетларында төрек, татар, гарәп телләрен, каллиграфия фәнен укыта. Шул рәвешле Х.Фәезханов профессор Мирза Казем-Бек йогынтысында Шәрык белгече буларак формалаша.

Х.Фәезхановны дин белгече дип тә санарга кирәк. Ул мәдрәсәләрдә укыту тәртибе,

киләчәктә аларның нинди булырга тиешлеге турында кайгырта. Әгәр татар дөньясы рус мәктәпләренә, рус дәүләтләренә конкурент булырга теләсә, аларның үз мәдрәсәләрендә рус телен һәм дөньяви фәннәрне укытырга тиешлеген әйтә. Тарихчы-галимнең атаклы бер хезмәте – татар мәгарифендә реформа кылу. Икенче яктан, Х.Фәезхановның татар тарихын өйрәнүгә, фәлсәфи, дини тәгълиматка багышланган кульязмалары да күп. Ул Россия мөселманнарын дини идарәләр нигезендә берләштерү, хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлек итү, җирле үзидарәдә катнашу моделен төзи. Моннан тыш, Х.Фәезхановның Казан ханлыгы, Касыйм ханлыгы, болгарларга багышланган тарихи әсәрләре яхшы мәгълүм.

Россия Фәннәр академиясе Х.Фәезхановка Мәскәүдәге Тышкы эшләр министрлыгы архивын тикшерүне тапшыра. Ул Петербург һәм Казан фәнни китапханәләрендәге гарәп, төрки, фарсы китапларының һәм кульязмаларының фундаменталь картотекасын да төзи, Кырым татарларына караган күп кенә материаллар алып кайта. Бу хезмәтләр алга таба Көнчыгышны өйрәнүдә төп ярдәмлек була. Академик В.Вельяминов-Зернов Кырым ханлыгының Россия һәм Польша белән мөнәсәбәтләре тарихына кагылышлы документларны эшкәрткәндә, аңа Х.Фәезханов ярдәм итә. Ике галимнең бердәм тырышлыгы белән 1864 елда «Материалы по истории Крымского ханства, извлеченные по распоряжению Императорской Академии наук из Главного архива Министерства иностранных дел» дип исемләнгән зур хезмәт дөнья күрә. Х.Фәезханов тарихи истәлекләр җыю, өйрәнү ниятеннән фәнни экспедицияләргә чыга, борынгы татар язмаларына тарих күзлегеннән һәм лингвистик анализ ясый. Тарихчы-галим 1860 елда Касыйм шәһәренә экспедициягә бара. Ул татар һәм гарәп язулы кырык кабер ташы таба. Х.Фәезханов шулай ук иске ярлыклар, грамоталар һәм болгар кабер ташларын өйрәнә. 1862 елдагы экспедициядә ул Тәтеш шәһәреннән ерак түгел урында өч кабер ташы таба, алардагы язуларга анализ ясап, бу хакта 1863 елда «Өч болгар кабер ташындагы язу» дигән мәкаләсен бастыра. Бу болгар-татар язуын һәм татар теленең формалашуын ачыклауда яңа мөмкинлекләр ача. Тарихчы-галим шулай ук, археологик һәм тарихи чыганакларны анализлап, хәзерге татарларның Идел-Кама буе болгарлары белән генетик кардәшлеген исбатлый.

Х.Фәезханов татар телен фәнни яктан өйрәнүдә күп эшли, «Татар теленең кыскача уку грамматикасы» дигән китап чыгара, төрки телләр сүзлеген һәм хрестоматиясен төзи. Х.Фәезханов үз хезмәтләре белән язма, әдәби телне сөйләм теленә якынайта.

Тарихчы галимнең 23 тел белүе, рус, чагатай, чуаш, мари, гарәп, госманлы, фарсы, төрек телләрендә язуы, иркен сөйләшүе мәгълүм. Х.Фәезханов, Фәннәр академиясе кушуы буенча, шәм яктысында меңләгән битле дини хезмәтләрне күчереп язган.

Х.Фәезханов 1855 елда Санкт-Петербургта чыгышы белән Рязань губернасы Касыйм өязеннән булган Бибифатыйма Бикиева белән никахлаша. Аларның беренче ике баласы кечкенә чакта ук вафат була. Кызлары Бибигайшә, Бибизәйнәп, Әминә – өчесе дә исән-сау үсеп җитә. «Алар үз вакытында яхшы гимназияләрдә белем алган, атаклы кешеләргә кияүгә чыккан, оныклары да мәгълүм кешеләр. Бер кызының нәсел дәвамчылары хәзер Германиядә һәм Төркиядә яши. Әмма безнең Хөсәен ага нәселеннән булган кешеләр белән очрашканыбыз юк. Энесе Габделгалләм нәселеннән кешеләр табылды», – ди Д.Мөхетдинов.

Х.Фәезханов гади гаиләдә туып-үскән, ягъни аның ата-анасы шәехләр дә, сәүдәгәрләр дә булмаган. «XIX гасырда гади татар авылында үскән егетнең шундый карьера ясавы бик кызыклы. Ул – Казан һәм Петербург университетларында укыткан татар кешеләреннән беренче дин, Шәрык белгече буларак тарих сәхифәләренә кереп калды. Әгәр Х.Фәезханов, 1866 елда сәламәтлеге какшау сәбәпле бакый дөньяга күчмәгән булса, Санкт-Петербург университеты профессоры дәрәҗәсенә ирешер иде».

Совет хакимияте елларында Х.Фәезханов исеме телгә алынмый. Әмма академик Миркасыйм Госманов, Риза Фәхретдиннең «Шура» журналы белән танышканда, Х.Фәезхановка багышланган берничә мәкаләгә тап була. Аларны укып, Х.Фәезхановның әсәрләрен, хезмәтләрен өйрәнеп, Р.Фәхретдин һәм Х.Фәезханов турында гыйльми хезмәтләр яза.

Х.Фәезханов туган авылы Сафаҗайда җирләнгән. Авылдашлары олуг дәрәҗәле якташлары турында белә, кабере саклана. Сафаҗай авылында мәктәп Х.Фәезханов исемен йөртә. Түбән Новгород өлкәсендәге Ислам институты да Х.Фәезханов исеме белән аталган. Галимнәр исә кульязмаларын өйрәнүне дәвам итә. Шәкертләр Х.Фәезхановның хезмәтләрен тикшереп, аның кульязмаларын карап, матур язуына, каллиграфия стиленә игътибар итә. Хөсәен аганың туган авылы Сафаҗайда да 2004 елдан башлап Фәезханов укулары үткәрелә.

Х.Фәезхановның күпчелек кульязмалары Санкт-Петербург китапханәсендә саклана. Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә дә Хөсәен Фәезхановның автографлары белән танышырга мөмкин. «Хөсәен Фәезханов. Хакыйкатькә тугрылык» дип аталган күргәзмәдә исә алар арасыннан милли мәгариф тарихына кагылган өч хезмәт куелган иде. Берсе – Х.Фәезханов тарафыннан эшләнгән мәдрәсәләрне реформалау проекты. Кульязманың кырыйларына Ш.Мәрҗани үз фикерләрен дә калдырган. Моннан аларның бергәләп татар мәгарифен тагын да яхшыртырга, алга җибәрергә теләүләре күренә.

(Дәвамы 16 нчы биттә).

Гаиләнең серле архивы

Гаилә архивыннан бабамның апасы белән сеңлесенең әниемә язган хатлары килеп чыкты. Алар арасында мин туган елда язылганнары да бар. Әнием яшь булгач, апалары киңәш биреп язган, үзләре язган җырларын да кушканнар. Ул җырларның кайберсен ишеткәнем бар, авылдагы апаларның елый-елый җырлаганын тыңлап, күңел моңсулана иде. Шул хатларның берсендә, әнкәй минем җиде айлык булып тууыма кайгырмасын өчен, аның күңелен юатып, Саҗидә апасы «абыебыз Хәкимхан да җиде айлык туды, бик җитез, уңган иде, 27 яшендә Бөек Ватан сугышында гына һәлак булды», – дип язган. Хәкимхан турында энидән сораштым, ул бабамның олы абыйсы булган, этиләре урынына калган егет икән, тик сугыш кырларыннан кайта алмаган… Шуңа күрәдер, аның бердәнбер сурәте олы, бизәкле көзге өстендә эленеп тора, кем керсә дә, аны күрә иде.

Бабайның апалары, үлгәнчегә кадәр, калай белән тышланган сандыкта Коръән белән бергә җыр дәфтәре саклый. Дәфтәр эчендә яңалиф графикасында язылган ике бәет бар, берсе «Хәкимхан бәете» дип атала. Аны улын сагынган әнисе язып калдырган.

Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы еллары күп кешеләргә авыр сынаулар алып килде. Әсма гаиләсен дә урап узмады бу язмыш. Сугышка кадәр Әсма ире Сәлах белән дүрт бала үстерә иде: ике кыз, ике ир бала. «Үзебез иртән торып уракта, аякта чабата, өстебездә киндер күлмәк булса да, тырыш гаилә идек. Умарталыгыбыз бар, сыер асрый идек», – дип исенә төшерде кызлары Хәбибә (аннары – Хәбибә апа).

1930 елда Хәбибә апа авыл татар мәктәбенең өченче сыйныф укуын тәмамлап килә. Шул елны авылларына кулак малын тарату дәһшәте дә килеп җитә. Өч гаиләне «кулак» дип куалар. Алар арасында Хәбибә апаның әти-әнисе, абыйсы белән энесе, өч яшьлек Саҗидә сеңлесе дә бар. Гаилә башлыгы үтенеч гаризасын сырлый: «Мине авылда һәммәсе белә», – дип яза ул, шуны раслап, авылдашлары да гариза астына кул куя, аның исемен пакьли. Авылның 1930 елгы «Совет бедноты» җыелышында аның крестьян хуҗалыгын үзе алып баруын таныйлар, аны гаиләсе белән колхозга кабул итәргә, дигән карар чыгарыла (ТР Милли архивы, П 8259 ф., 1 тасв., 5 эш, 37-38 бб.). Ләкин, үкенечкә, ялгышлык килеп чыга. «Ат арбасына барыбызны утыртып алып киттеләр, үзебез өске киемнән генә идек», – дип хәтерли Хәбибә апа. Гаиләне Свердловск өлкәсендәге Серов шәһәреннән 12 чакрым ераклыкта булган тайгада урман кисәргә сөргенгә урнаштыралар. Сөргендә тиф чире күп кешеләрне аяктан ега, чирдән арына алмыйча, гаилә башы Сәлах дөньядан китә.

Әсма, дүрт баласы белән, үзе тәсле үк куылганнар белән бер баракта кала. Анда яшәрлек түгел, идән – җирдән, көн саен мәет. Әсма үзе дә тиф белән авырый. Ул бер ел Серов шәһәрендәге хастаханәдә дәвалана. Балалары бер елга абыйлары карамагында кала.

16 яшьлек абыйлары Хәкимхан, землянка казып, туганнарын үлемнән коткара; салкын кышны шунда чыгалар. Ике ел үткәч, «Монда ире булмаганнар исән кала алмый, китегез!» – дип киңәш бирә сөргенлеләр. Әсма балалары белән туган авылына кайтырга була. Поездга утырып китәләр. Кайткач, Хәкимханның 18 яше тулганы ачыклана, яше җиткән булганга, авылларына кертмиләр. Егет кире китә.

Туган җиргә кайткач, Әсма балалары белән өч ай су буенда яшәп, хәер сораша. Салкыннар башлану белән, ана кеше колхоз рәисе (Мөбарәкша Әхмәтшин) янына бара, тезләнеп ялвара. Балалары яшь булганга микән, кышка үз нигезләренә яшәргә кертәләр. Ике катлы агач өйдән мәктәп салынган, таш кладовойдан – юл. Гаилә калган балчык кладовойга яшәргә керә, Бөек Ватан сугышын шунда каршылый. Бу вакытта Хәбибә апа эшкә кергән була инде, сеңлесе мәктәптә укый, энесе Галимҗан 1941 елда 8 сыйныф тәмамлый. Шул елның җәйге көнендә 17 яше тулган Галимҗанны сугышка, беренче Белорус фронтының танк дивизиясенә алалар.





● Сәлах Газиз улының үтенеч гаризасына авылдашлары кул куйган бит. Милли архив, П 8259 ф., 1 тасв., 5 эш, 34 б.

«Җәй ахырында Чистай пристаненнан озаттык», – дип сөйли иде Хәбибә апа. Әсма олы улы Хәкимханнан хатлар ала. Ул өйләнгән, Хабаровск шәһәрендә эшли, әнисенә, туганнарына посылкалар сала. Хәкимханга 27 яше тулган чакта Әсмага хат килә: «Мине сугышка алалар». Бу әнисенә язган соңгы хаты була. Хәкимханның хәбәрсез югалуы ачыклана. Газиз ана улыннан көне-төне хат көтә, үлү хәбәре юк, димәк, исән дип өметләнә.

Әсма 1955 елда дөньядан китә, аннан үз кулы белән язган сагыну хатлары, җырлары, бәетләре кала.

Әсманың кече улы, өлкән сержант, механик-йөртүче, бөтен сугышны ерып чыга, Берлинга кадәр барып җитә. Бөек Ватан сугышы вакытында танк экипажы белән Днепрны кичү операциясендә катнаша. Курск дугасы янындагы бәрелештә ныклык күрсәтә, әмма бу хәлләрне искә төшергәндә, бабайның күзләренә яшьләр килә иде. Хәер, егерме яшьлек егет кенә булган бит ул вакытта. Бер-бер артлы шәһәрләрне азат итеп, Будапешт, Флорисдорф, Дьер, Комаром, Знойно, Брно, Прага шәһәрләрен, немец оборонасының стратегик төенен – Вена шәһәрен азат иткән өчен, И.В.Сталинның Рәхмәт хатлары белән билгеләп үтелә. 1945 елның апрель башында аның танк дивизиясе Польшаны азат итә. Бабамның истәлеге буенча, аның Т-34-85 танк экипажы Прага шәһәренә беренче булып керә. Шәһәр халкы азат итүчеләрне канәфер чәчәкләре белән каршы ала. Хәрби машина Прагада берничә урында «яраланган» булганга, аны яңага алыштыралар, искесен танк һәйкәле буларак калдыралар. Бу вакытта экипаж исәбендә юк ителгән 12 фашист танкы була. Хәрби машинаның барлык экипажы Дан орденына лаек була. Җиңү парадын экипаж Берлинда үткәрә. Галимҗан сугыштан 1947 елда гына кайта.

Бу зирәк зиһенле егетне Советлар Союзы Маршалы К.К.Рокоссовский да күреп ала, үз янына чакыра, тик ул әнисен кызгана. Галимҗан авылда кала. Сугыштан соң ул туган авылында кирпеч сугу заводын төзергә тәкъдим итә. Галимҗан, минем дәү әтием, совхозда җитәкчелек эшен алып бара, кирпеч сугу эшендә мөдир була. Җәй җитүгә, без оныклар бабайның мотоциклга утыртып заводка алып барганын көтә идек.

1992 ел, көзнең салкын көне иде. Галимҗан бабайны җирләргә бөтен авыл кешесе җыелды. Бу гади генә җеназа түгел иде, бер гасыр кешесен озату иде. Авылдашлары өчен үрнәк булган зат, ярдәмче, акыл иясе. Ни булса да, бабам: «Кеше таш белән атса, син аш белән ат», – дип әйтә иде. Шуңа күрәдер, мөгаен, җирләгәндә янына бик олы яшьтәге бер ханым килде… Мәетне сыпырды да, үзенә генә ишетелерлек итеп әйтте: «Гафу ит, Галимҗан». Бу – заманында Әсма ялварган председательнең хатыны иде.

Эльмира ХУҖИЕВА.

КЕШЕ МИН...

Кеше мин...
Күңелем бик нечкә.
Рәнҗетмәгез җанымны – тимәгез,
Елатырга бер авыр сүз җитә.
Кеше мин...

Кеше мин...
Ләкин кешеләрдән куркам.
Бүре сыман ташланалар бер-берсенә,
Ни көтәсең син, әй, дөнья,
Акча тузанына баткан кешедән?
Кеше мин...

Кеше мин...
Бер-беребезгә хөрмәт саклыйк,
Ярдәм итик, – мин үтенәм.
Җанны әвәләмик сазга.
Ни әйтермен Аллаһ алдында
Әгәр Кешелекне –
Төрә алмасам назга?
Кеше мин...
Бары тик – кеше...

* * *

Җир өстендә җилләр йөри,
Кемне алар эзлиләр?
Әллә кеше язмышларын,
Сакта торып, күзлиләр?!

Кешеләр дә җилләр кебек –
Кайларгадыр юл тота?
Язмышларның эзләреннән
Хәтер башын калкыта.

Канатлы җилләр исәләр,
Өметләре – күктәдер...
Һәммә кеше бу тормышта
Җил юлларын үтәдер...

* * *

Вакыт ага.
Ул битараф күптән,
Бар дөньяның уен беләэ ул.
Тигезлидер бары галәм генә,
Иксез-чиксез, ерак озын юл...
Мәңгелекнең чиген күреп булмый,
Вакытларга чорлар үрелгән.
Күзем йомдым.
Җанны җылытырга
Соңгы өмет-хыял бирелгән.
Бәлки, миндә шушы халәтемнең
Югалтулар кичкән салкыны...
Өметемне саклап йөрәгемдә
Яшим!
Һәм син дөрлә,
Яшьлек ялкыны!
Килер бер көн,
Минем тормышымда
Йолдызларым балкыр тагын да!
Мин яшьлекнең эзен эзлим бүген
Төн озатып алсу таңымда...

ХАТЫН-КЫЗ – СЫЛУ ЧӘЧӘК!

Хатын-кызның карашында
Күпме наз – искитәрлек!
Көләч йөзе нур сибәдер,
Бар дөньяга җитәрлек.

Күзләрендә серле дөнья –
Мәхәббәт алиһәсе...
Һәр хатын-кыз – ул бердәнбер,
Гүзәл анын һәммәсе.

Кемнәр генә сокланмыйдыр!
Зифа, сылу, төз буе.
Сабырлыгы белән матур
Хатын-кыз гомер буе.

Гүзәллеге, күркәмлеге,
Шәһрезадә, диярсең.
Хатын-кызның бәхетенә
Күзләр генә тимәсен!

Юмарт та ул, хыялый да,
Җылы, назлы кочагы.
Хатын-кызның күңелендә
Хисләр – ялкын учагы!

Сагышлы да, моңсу да ул,
Әллә күңел туламы?
Хатын-кыздан башка җирдә
Бәхет табып буламы?!

Аннан башка булмас яшәү,
Ул – тормышның дәвамы.
Хатын-кызлар – ул әниләр,
Өләшүче дәваны...

Рәнҗетмәгез, елатмагыз,
Хатын-кыз – сылу чәчәк.
Хатын-кыздан башланадыр
Җир йөзендә киләчәк!

Алия ЗӘРТДИНОВА

Алия Зәртдинова 1983 елда Түбән Кама шәһәрендә дөньяга килә.

Каланың Бакый Урманче исемендәге 2 нче татар гимназиясендә укый, аннары Мәскәү гуманитар-икътисад институтын кызыл дипломга тәмамлый. Казан Социаль белем бирү академиясендә аспирантурада укый. 2006 елда юридик фәннәр кандидаты була.

Шигырьләрне мәктәптә укыганда ук яза башлый. Күп кенә шигырьләре Түбән Камада чыга торган татар газеталарында, «Кама таңнары», «Чулман акчарлаклары» күмәк җыентыкларында дөнья күрә. Алия – ике шигырь китабы авторы.

Бушатырга күңелемнең йөген Хәрефләрне тезәм сүзләргә...

* * *

Серең булып калыйм күңелеңдә,
Караңгы төн юлым кисмәсен.
Мин утырткан бакча гөлләреңә
Салкын кырау гына тимәсен.

Йөрәгемнән күчкән назларымның
Сизәрсеңме сөю ялкынын?
Язларымда чәчәк аткан чакта,
Тидермәсәң иде салкынын...

Тик без генә белгән сөюләрнең
Бәхет эзен салам төннәргә.
Сиңа булган керсез мәхәббәтем
Сыенгандыр шушы гөлләргә.

* * *

Безне Кояш артык сөйдә бугай.
Син дә, мин дә һаман шул ук тиле!
Күз карашым аша иркәлидер
Йөзләреңә кунган август җиле.

САУМЫ, ДӨНЬЯ!

Саумы, Дөнья!
Син гел әйләнештә.
Минем җанда әле көнем исән.
Ниләр булыр бүген?
Ә иртәгә
Кайсы якка таба җилләр исәр?

Нурлы Дөнья!
Кирәктер яшьнәвем!
Нинди мәгънә иләс-миләс көннән?!
Ташып чыксын әйдә өмет булып
Яшәү көчем,
Иркем
Күкрәгемнән!

Дөнья фани, диләр.
Мин килешәм.
Шөкер әле, һәр сулышым тирән!
Һәм мин яшим көнем-төнем, уем,
Бар белгәнем –
Шушы Дөньям белән!

* * *

Һәр юлның үз юнәлеше...
Туфрагы да бар, ташы.
Бер сукмактан башланадыр
Гомерләрнең юл башы.

Алда көтә төрле юллар...
Сукмаклары кушыла.
Яши-яши, атлый кеше,
Чыгам, диеп, очына.

Шул юллардан китәр өчен,
Күперләр җәеп сала.
Вакыт узгач, үткәннәрнең
Эзләре генә кала.

Кеше гомер буе бара...
Туктатырга юк чара!
Бертуктамый, яшәр өчен,
Ул һаман алга чаба!

ЯҢА ХИСЛӘР КИРӘК

Яңа хисләр кирәк!
Эзләнүләр...
Сагынмыйм ла ерак үткәнне.
Күрәсеңме, күктә кояш калка,
Җылылыкка төреп көннәрне.
Бар да исән!
Җирдә өмет яши!
Иңнәремә төшә кояшым
(Кояш кына мине аңлый кебек,
Кояш кына якын юлдашым).
Аһ бу Дөнья!
Тыгыз әйләнештә:
Өлгерергә иде ничек тә!
Балтырларга пычрак сыланадыр,
Ә мин һаман басам чүплеккә...
Эзлим чара...
Каян табыйм җавап?
Мең уйлардан башым иелсә,
Кояшымны кочып атлар идем,
Әгәр җанда бозлар эресә...
Авыз тулы авыр сүзләр йөгә...
Тик елмаю әле сизелә.
Үзәгемдә кайнар канлы яшем
Кипте. Бетте. Җанга җиңелрәк...
Юлым якты.
Мин кояшка карыйм,
Очар өчен өскә биегрәк....
Һәр көн саен яңа шатлык көтәм
Иркен күкрәк белән сулардык.
Күз алдымда – нурлар чагылышы
Һәм яктылык...
Бары... яктылык!
Күктә – кояш...
Әгәр күзләр минем
Ябылса да арып берзаман,
Үз җилкәңне тереп өлгер өйдә,
Өметемне акла,
И Заман!

Тыннарыңны тыннарыма кушам.
Яшер мине, җаным, иң түренә!
Кояш нуры сөйгән күзләреңнең
Яктылыгын салам күңелемә.
Очраштык...

* * *

Җанымда тибрәләдер һаман,
Минем хисемдер ул, минем хисем.
Онытырга буламы соң сине?
Шул ук исем инде, шул ук исем...
Бушатырга күңелемнең йөген
Хәрефләрне тезәм сүзләргә.
Исемеңне уйларымда йөртеп,
Мин күңегәм сабыр көзләргә...

МИН ЯЗЛАРНЫ АЛЫП КИЛӘМ СИҢА...

Мин язларны алып киләм сиңа,
Хисләремнән күккә калкырмын.
Иң бәхетле, татлы мизгелләрдә
Үз кояшың кебек балкырмын!

Мин язларны алып киләм сиңа,
Яшь таҗларын сөеп гөлләрнең,
Шушы язның матурлыгын эзлим,
Ишекләрен ачып көннәрнең.

Мин язларны алып киләм сиңа,
Күлмәк төсе булыр гел актан.
Якты нурдай зәңгәр күкләремдә
Туармын күк бүген кабаттан.

Мин язларны алып киләм сиңа,
Салкыннардан ахры котылам.
Йөрәгемне биләп алган хискә,
Җылылыкка, назга омтылам!

Мин язларны алып киләм сиңа,
Киләчәкне ямьләп, кузгатып.
Ярсып типкән көйсез йөрәгемне
Кабат-кабат шулай сызлатып...

Мин язларны алып киләм сиңа,
Шатлыкларга тулып бушанам.
Әллә язлар миңа ышаналар?!
Әллә үзем язга ышанам...

Башкортстанда туган

Безнең халык 75-80 ел буена: «Татарстан совет иленә 200 дән артык Советлар Союзы Герое үстереп биргән, шуның 172 се – татар; бик урынлы, әле бөек Тукай ук «Без сугышта юлбарыстан көчлебез», дип газиз милләтенең данын яклаган бит», – дип шапырынырга үтә ярата. Без – гаҗәеп халык: күпчелек очракта «Татарлар бөтен дөнья буйлап чәчелгән», дип күкрәк сугабыз, татар конгрессына да, әнә, «Бөтендөньяныкы» дигән мөһер чәпәп куйдык. Әмма менә тарихны ачыкларга туры килсә, Татарстаннан читкә атлап, бернинди археологик казу эшләре алып барырга ашкынмыйбыз. Галимнәребезнең, республикадан читкә чыгып, беренче чиратта Башкортстандагы, аннары инде борынгыдан бирле татарлар күпләп яшәгән Төмән, Саратов, Самара, Оренбург, Курган, Киров, Чиләбе, Свердловск, Әстерхан, Волгоград өлкәләре, Пермь крае, Кырым, Чуашстан белән Удмуртия республикаларындагы татар авылларының зиратларындагы кабер ташларын, алардагы язуларны да инде өйрәнгәне юк. Ике төрле бизмән, ике төрле гамәл. Шапырынган чакта – «Бөтендөньяныкы», ә тарихны күтәргәндә – республика чиген атлап чыга күрмә, аннары Мәскәү ни әйтер дә, ут күршеләр безгә рәнҗемәсме? Иллә мәгәр, шул ук безгә терәлеп торган Башкортстанда синең мин-минлегенә яки тыйнаклыгыңа төкереп тә бирмиләр, 1855 елдан бирле татарны гына түгел, хәтта мари белән удмурт авылларында яшәгән халыкны да җанисәп вакытында хөкүмәт көче белән башкортлаштыру, татар тарихының юрганын да үз якларына тарту, талау дәвам итә.

Янә кабатлыйк: Татарстан 200 ләп герой үстергән, дидек, ә Башкортстан менә 282 каһарман бүләк иткән икән. Әмма Уфа галимнәре Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышлап 2020 елда чыгарган «Подвиги их – бессмертны» дигән китапларындагы исемлеккә 1937 елда Испаниядә Франко хөкүмәтенә каршы сугышта танк командиры буларак катнашып Герой исеменә лаек булган А.В.Никоновны да, 1956 һәм 1979 елларда Венгрия белән Әфганстанга басып кергән, 1986 елда Чернобыль атом станциясендәге аварияне юкка чыгаруда катнашкан 8 якташларын да кушып куйган. Аннары шушы ук исемлектә 1992 елдан соң гына Россия Герое исеменә лаек булган 30 якташ, ә азакта инде Дан орденнарының тулы кавалерына әверелгән 47 каһарманның исем-фамилияләре тезелеп китә. Әгәр биографиясе теге яки бу яклап Татарстан белән бәйле геройларны санасаң, бездә андыйларның саны 343 кә җитә. Ләкин Уфа галимнәренең, 1941-1942 елларда эвакуацияләнеп килгәч, ярты яки бер елдан соң фронтка юл алган яисә инде Уфада ачылган хәрби училищеларда укып киткән каһарманнарны үзләренә беркетергә маташуы – башкорт халкына, гомумән дә, бернинди дан-шөһрәт өстәми.

Ә инде фәкать Бөек Ватан сугышы фронтларында батырлык күрсәткән геройлар исемлеген барлый башласак, Башкортстандагы каһарманнар арасыннан икесенең берсе – валлаһи-дыр, татар!

Иң әүвәл, сүзне ике мәртәбә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган очучы **Муса Гәрәев**тән башлыйк. Уфа мөтәгалимнәре һәм Мортаза Рәхимов канаты астындагы милләтчеләр аны ничә дистә еллар буе: «Безнеке, башкортныкы!» – дип күкрәк сукса да, лачын Муса бүген 80 процент халкы «башкорт»ка әйләндерелгән, әмма сыңар гына да башкорт авылы булмаган Илеш районының Иләкшиде дигән төбәгендә туып-үскән. Без шушы Иләкшиденең үзендә дә, 1929 елда аннан күченгән Ташчишмәдә, алар өстеннән жирле үзидарә үзгәге булып торган Бишкурай авылларында да, район үзәге Яркәйдә дә озак еллар дәвамында дистәләгән мәртәбәләр булдык, ләкин көндез чыра яндырып эзләсәк тә, анда башкортча сөйләшүче яки үзен башкорт дип танучы сыңар жан иясен дә таба алмадык. XVII-XIX гасырларда Илеш төбәгендәге халыкның күпчелеге чәчүлек жирне һәр ир башына 40 ар дисәтинә күләмендә эләктерү максатыннан «башкорт катламы»на язылса да, 1920 һәм 1926 елларда үткәрелгән тәүге совет җанисәпләре вакытында ук аларның һәммәсе үзен «фәкать татар!» дип танымыйча калмый.

Шул ук районның Иске Дөмәй (төп утары Сарман районының Дөмәй-Тарлау авылында, ә үзе шул зур төбәк старшинасы, өстәвенә әле 1704 елда бик зур азатлык явы башлаучыларның берсе булган, әмма 1708 елда патша карательләре тарафыннан дар агачына асып үтерелгән Дөмәй Ишкәев атлы каһарман исемен йөртә) авылыннан чыккан **Әнвәр Абдуллин** да – һичбер шиксез татар! Ул әле сугыштан соң Кырмыскалы райкомында секретарь булып та торган, «башкорт» булса, аны тоташы белән диярлек татар авылларыннан хасил халык санга сугамыни?.. Миякә районының (бөек Акмулла һәм Айдар Хәлимнең ватаны) Кыргыз-Миякә авылында туган **Мансур Абдуллин** да – татар, югыйсә аны тоташы белән диярлек татар Стәрлебаш районының үзәк мәктәбенә директор итеп куярлар иде микән?..

«Подвиги их – бессмертны» китабына барып эләккән **Фәйзулла Әһлетдинов** тумышы белән Азнакай районының (хәзер Бакалыда) Сасы Күл авылыннан (газиз Фәез Зөлкарнәй һәм аның энесе Ләис туган нигез), фронтка Туймазы хәрби комиссариаты аша чакырылган, 1988 елда шул ук Туймазыда җирләнгән. Татарлыгын исбатлап торасы юк.

1943 елда 24 яшендә һәлак булган **Хәмит Әһлиуллин** – Благовар районының Үдрәкбаш авылыннан. Минем әнкәйнең бертуган апасы Зифа-зуринәй 1960 елларда шул авыл мәктәбендә укытты, җәйге каникулларда янына барып йөрдем, тирә-юньдә сыңар гына башкорт та очратмадым.

20 яшендә Днепр елгасын кичүдәге батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исемен яулауга ирешкән **Мәхмүт Актуганов** – Мишкә районының Яңа Сафа авылыннан. Рейхстаг түбәсенә иң беренче булып Җиңү байрагы кадаган, әмма татар булган өчен генә Герой исеменнән колак каккан Гази Заһитовның туган авылы Яңакуыш – янәшәдә генә. Мишкә районындагы татар авылларының күпчелеген Башкортстандагы Чишмә районыннан күчкән мишәрләр нигезләгән.

Одер елгасын кичүдәге батырлыгы өчен 21 яшендә Герой исеменә лаек булган **Гайфетдин Аскин** – Нуриман районының Чураш авылыннан. Район үзәге Кызылъярны, ул райондагы Байкилде, Бикморза, Теңкәш, Олы һәм Кече Шиде авылларын тулысынча Актаныш районыннан күченгән татарлар нигезләгән. Ул районда Иске белән Яңа Күл авыллары гына башкортныкы булып исәпләнә.

Украинаны азат итү өчен яулар барышында батырлык кылган **Закир Әсфәндияров** – Гафури районының Үтәк авылыннан. Үтәк – XIX гасыр ахырында данлыклы мәдрәсәсе белән танылала, анда бөек Ш.Мәрҗанидә белем алган Хәбибназар Сатлыков, Шәфыйк ахун, Мөхәммәткафи хәзрәт белем бирә. Зәки Вәлидинең әтисе Әхмәтша әнә шул Кафи хәзрәтнең кызына өйләнә, үзе дә Көзән авылында мәдрәсә ачып җибәрә, ә улы Зәкине Үтәк мәдрәсәсенә илтеп укыта. Шушы мәдрәсәне тәмамлаган Габдрахман Гомәри хәзрәтләре соңыннан Әстерхан каласының Тияк бистәсендәге мәчеттә имам булып тора, 1906 елда «Идел» дигән газета да чыгара башлый. Һәммә эшкә берүзе җитешә алмагач, Казаннан атаклы шагыйрь Сәгыйть Рәмиевне чакырта һәм «Идел» газетасын аның кулына бирә. Кыскасы, Үтәк авылы – Ишембай-Гафури төбәгендә яшәүче татар халкының мәгърифәт үзәге ул.

Беларусь белән Литваны азат итүдә каһарманлык кылган **Фасылҗан Акмалетдинов** – Кушнаренко районының Әхмәт авылыннан. Бу райондагы 79 авылның берсе, Гарибаш (Гәрәйбаш) кына 1861 елда Актаныш районыннан күчеп килгән удмуртлар авылы, башкалары барысы да – татар.

Габит Әхмәров – Федоров районының Иске Чытырман авылыннан. Герой исеменә 23 яшендә, 112 нче Башкорт дивизиясе составында Украинаның Чернигов өлкәсен азат итүдәге батырлыклары өчен лаек була (дивизия үзе дә әүвәл 16 нчы «гвардия», аннары Чернигов исемен ала). 78 Герой составында Әхмәровның исеме дә дивизия хөрмәтенә куелган мемориаль такталарга уелган.

Зәйнетдин Әхмәтҗанов – Гафури районының Ялгызкаен авылыннан. Висла елгасын кичүдә һәм Польшаны азат итү өчен яуларда батырлык үрнәге күрсәтә. Гафури – тулысынча диярлек татар районы.

Габдулла Әхмәтов – Стәрлебаш районының Юмагуҗа авылыннан. Днепр кичүен өзлексез телефон линияләре белән тәэмин итә. Сугыштан соң Айтуган һәм Стәрлебаш мәктәпләрендә укыта, Стәрлебаш район советында рәис урынбасары булып эшли.

Миңнулла Бәдретдинов – Тәтешле районының Чыргылды авылыннан. Украинада, Днепр елгасын кичү өчен яуларда һәлак була. Тәтешле районында сыңар гына башкорт авылы да юк.

Солтан Бикеев – Әлшәй районының Габдрәшит авылыннан. Совет-фин бәрелеше һәм Украинаны азат итү өчен яуларда катнаша. Сугыштан соң Башкорт-

татар Геройлары

стан Югары Советы аппаратында эшли, Уфада 2 нче типографияне җитәкли.

Хөдәт Булатов – Әлшәй районының Чебенле авылыннан. Беларусьның Гомель өлкәсен азат итү өчен яуларда батырлык кыла. Исеме 112 нче Башкорт дивизиясенең мемориаль тактасына теркәлгән.

Салих Вәлиев – Кушнаренко районының Иске Гомәр авылыннан. Совет-фин сугышында катнаша, 1943 елның сентябрендә Днепрны кичүдә һәм Киев өлкәсен азат итүдә батырлыклар кыла.

Габдулла Вәлиев – Кушнаренко районының Бакай авылыннан. Ленинград өлкәсенең Гатчина районын азат иткәндә танкка ату мылтыгыннан дошманның 6 пулемет ноктасын юк итә, үзе 21 яшендә һәлак була.



Фәйзулла Габдерәшитов – Туймазы районының Иске Кандра авылыннан. Тачанкасы белән Украинаның Чернигов өлкәсендә батырлыклар кыла. Исеме 112 нче Башкорт дивизиясенең мемориаль тактасына уелган. Сугыштан соң ул чип-чиста татарныкы булып саналган Бүздәк районында эшли.

Хәмит Гаделшин – Бишбүләк районының Ает авылыннан, атаклы Фатих Кәрим якташы. Дала фронты составында Украинаны азат итү өчен яуларда таныла. Сугыштан соң да армиядә кала, полковник дәрәҗәсенә ирешә.

Сәлимҗан Галимҗанов – Аскын районының Төлгәбаш авылыннан. Дала фронты составында Днепр елгасын кичүдә һәм Украинаның Днепропетровск өлкәсен азат итүдә катнаша. Сугыштан соң Екатеринбург каласына күченә.

Вахит Галимов – Чакмагыш районының Иске Балак авылыннан. 3 нче Украина фронты составында Днепр елгасын кичүдә, Днепропетровск каласын азат итүдә батырлыклар кыла, 22 яшендә һәлак була.

Шакир Гатиатуллин – Октябрьск районының Мулла авылыннан. 112 нче Башкорт дивизиясендә кылычлылар взводының командир урынбасары. Днепр елгасын кичүдә һәм Беларусьның Гомель өлкәсен азат итү өчен яуларның берсендә батырлыклар кылып һәлак була. Исеме 112 нче Башкорт дивизиясенең мемориаль тактасына язылган.

Габдулла Гыйззәтуллин – Чишмә районының Ибраһим авылыннан. Днепр елгасын кичүдә һәм Гомель өлкәсен азат итүдә батырлыклар кыла, әмма 1945 елның 15 мартында һәлак була. Исеме 112 нче Башкорт дивизиясенең мемориаль тактасында теркәлгән.

Таҗетдин Гыйләҗетдинов – Борай районының Олы Бәдрәк авылыннан. Бәдрәк әле Пугачев явы чорында ук фетнәче милли отрядларның бер үзәге буларак тарихи документларга әләгә. Ә лейтенант Т.Гыйләҗетдинов Кырымның Җанкай районын һәм Севастопольне азат итү өчен яуларда таныла. Сугыштан соң үз авылының мәктәбендә укыта, районның мәгариф бүлеген җитәкли, партиянең райком секретаре булып эшли.

Миңлегали Гобәйдуллин – Миякә районының Үршәкбаш-Карамалы авылыннан. 1943 елда Днепр елгасын кичүдә һәм Украинаның Херсон каласын азат итүдә катнаша. 1944 елның 8 мартында Херсон өлкәсенең Дудчан авылы янында үз күкрәгә белән дошман амбразурасын каплый.

Бакир Дәүләтов – Благовар районының Иске Әмир авылыннан. 15 яшендә үк Кыргызстанга күчеп китә, шуннан фронтка чакырыла. 112 нче Башкорт дивизиясендә станоклы пулеметтан атучы булып, Днепрны кичүдә һәм Беларусьның Гомель өлкәсен азат итүдә батырлык кыла. Сугыштан соң янә Кыргызстанның Турсунзаде каласына кайтып китә. Исеме 112 нче Башкорт дивизиясенең мемориаль тактасына уелган.

Әхмәт Закиров – Борай районының Кашкалы авылыннан. 1943 елның сентябрендә Днепр елгасын кичүдә һәм Беларусьның Гомель өлкәсен азат итүдә таныла. Сугыштан соң Уфада гади машинист булып эшли.

Гыйлемхан Идрисов – Благовар районының Яңа Әбзән авылыннан. 1 нче Украина фронтында орудие командиры. Польшаны азат итү вакытында күп батырлык кыла. Сугыштан соң әүвәл авыл советы рәисе булып эшли дә Казахстанның Шымкент каласына күченеп китә.

Мәгъсүм Имаметдинов – Яңавыл районының Кызылъяр авылыннан. 1 нче Украина фронтында сугышып, Польшаны азат итүдә, аеруча Одер елгасын кичкәндә батырлыклар күрсәтә, ләкин һәлак була.

Ишмай Ишкинин – Мишкә районының Ишем авылыннан. Кенигсберг каласын яулау өчен сугышларда батырлык күрсәтә.

Гатият Ишкулов – Федоров районының Яңа Яуш авылыннан. Үзйөрешле артиллерия установкасы командиры, өлкән лейтенант. 1944 елның декабрендә Чехословакияне азат итү вакытында үз установкасы белән дошман оясына бәреп керә, аларның орудиеләрен һәм пулемет нокталарын юк итә, әмма һәлак була.

Габдрахман Латыйпов – Чакмагыш районының Иске Бәшир авылыннан. 1945 елның гыйнварында Одер елгасын кичүдә һәм Польшаның Вроцлав каласын азат итү вакытында батырлыклар күрсәтеп һәлак була.

Котдус Латыйпов – Мәчетле районының Яңа Мишәр авылыннан. 1941 елда Свердловск авиация училищесын тәмамлый. Әүвәл звено командиры. Шул звено составында күп мәртәбә дошман позицияләрен бомбага тота, Украинаны азат итүдә катнаша, Яссы каласы янындагы яуларда күп батырлык күрсәтә. 1946 елның 15 маенда Герой исеменә лаек була. Сугыштан соң авиаполк командиры урынбасары, дивизиядә политбүлек башлыгы, полковник.



Гали Мәҗитов – Ярмәкәй районының Яңа Шаһ авылыннан. Сугышка кадәр үк Казан һәм Оренбургта хәрби очучылар училищеларын тәмамлый, сугыш вакытында дивизиянең баш штурманы дәрәҗәсенә ирешә. Дошман көчләрен юк итү өчен, Германия һәм Финляндия территорияләренә хәрби очышлар ясый. Сугыштан соң подполковник Г.Мәҗитов Ялтага күчеп китә.



Сәхиб Маһубгалиев – Борай районының Бигәнәй авылыннан. Совет-фин сугышы ветераны, батальон командиры, капитан. 1940 елның февралендә Ленинград өлкәсенең Күл буе районында, дошман туктаусыз ут яудырып торуга карамастан, финнарның бер авылын яулап ала, әмма һәлак була.

Шакирҗан Мөхәммәтҗанов (Александр Матросов) – Учалы районының Кунакбай авылыннан. 1943 елның февралендә Псков өлкәсенең Чернушки авылы янында үз күкрәгә белән дошман амбразурасын каплый.

Нурлы Миңлеәхмәтов – Караидел районының Аскыш авылыннан. 1943 елның сентябрендә Десна елгасын кичүдә һәм Украинаның Сумы өлкәсен азат итүдә батырлыклар кыла. Сугыштан соң үз районында колхоз рәисе, ахырда умартачы булып эшли.



Гомәр Миңлебаев – Бүздәк районының Урзайбаш авылыннан. Бу районда Канлы-Төркәй атлы авылдан тыш, бер генә башкорт авылы да юк. Гомәр – авиация полкында эскадрилья командиры урынбасары, өлкән лейтенант. 1945 елның 23 февралендә аңа Герой исеме бирелгән. 1959 елда запаска чыгарылгач, Уфада, Алматыда, Краснодар краеның Геленджик каласында эшләгән.

Зәйнулла Мөстәкыймов – Шаран районының Юмадыбаш авылыннан. 1 нче Балтыйк буе фронтында Литва җирен азат иткәндә, үз батареясы белән дошманның 10 танкын юк итеп, каһарманлык күрсәтә, әмма үзе 1945 елгы февраль аеның соңгы көнендә һәлак була.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Мәдәни җомга
16 июнь
№23, 2023

(Дәвамы. Башы 20, 21, 22 нче саннарда).

МОСТАФА

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

Мостафа җил якланып урыныннан купты, башына килгән беренче уйны кычкырып җибәрде: «Болай итик, эти. Күпме чиләнергә була авылда? Тотасың да калага күчеп киләсең. Тегеләрне әйтәм, Муллинны, бер ябыштырсалар, ансат кына ычкындырмаслар. Китеп котыл! Шәһәрдә югалырга да була. Бергә-бергә яшәрбез. Карт-корыга, эшлим дигәндә, эш бетмәгән!»

Һәрчак җиде кат үлчәгәч кенә кисәргә гадәтләнгән зирәк карт соң дәрәҗәдә гаҗәпләнде, йокысыз аунаганда чәбәләнгән сакалын калтыранган бармаклары белән тарый-тарый, улына чиксез рәнҗеде. «Ни тиле тәүкәлдәй кыланасың? Картаймыш көнемдә иманлы нигеземне ташлап чегән арбасына тагылган дегет лагунына әйләнимме? Картлыкта имансызлар гына туган төякләренә төкереп газиз сөякләрен теләсә кайда таратырга, кадерсезләргә чыгып китәләр. Адәм ышанмастайны хак булса да телеңә кертмә!» дип ватылып уйлады ул, уйларын улына да чыгарып салмады, яшьтән үк үзеннән читләшкән Мостафа белән бер бүген генә якыная алмасларын сизде.

Иртә торган килен ул арада тәче коймак өлгерткән, күкәй тәбәсе куырган, хуш ис таратып чәй пешергән иде. Кетердәп пешкән кәрәзле коймакны каймакка мана-мана әчен җылытып, җанына терәк өстәгәч, карт әз-мәз җанлангандай булды, гозерен кабатлап вакланмады, улына рәнҗүен сиздермәде, чәйдән соң ук юлга җыенды. Килен исә йомшак кына рәнҗеде. «Эти, – диде ул, әйтер олы сүзе барлыгын сиздергән сыман моңсу тавыш белән, – яңа суйган сарык итеннән пилмән бөктем, шулпалы бәлеш утыртам, бик ашыксаң да ашап китәрсең. Кун тагын берне! Болай ай күрде – кояш алды!» Халисәнең эткәсенә ачылып бер зарланасы, бушанасы килә иде. Ире хакында сыннар сүз чыгармаган хатын гаиләнең иң олы кешесенә – эткәсенә ачылып китәргә, зар-моңнарын түгеп җиңеләергә өзер иде. Халисә инәлсә дә, картның кирелеге җиңде, ул кабыл-тибел киенде дә Үсиягә пароходка төшеп китте. Тәртип буенча Мостафа этисен озата төшәргә, билет юнәтеп пароходка кертеп үк утыртырга тиеш иде. Ләкин ул, этисенең кинәтлегеннәнме, йомышын үти алмау гарьлегеннәнме йончыган бәндә, аягын өстерәп кенә йөрткән картның авыр карашын күтәрә алмады, шунда, трамвай тукталышында кул болгап кына озатып калды. Бер трамвай үтте, икенчесен күздән үткәрде Мостафа, эткәсе аның дөнья авырлыгыннардай згыйфьләнгән күңеленә китмәс уй салып калдырды. Теленә акыллы сүз чакырып, адымнарын санап кына кайтса да, күңеленә дөрес җавап иңмәде: картны бу бәладән ничек аяп алырга?

Көн уйлады, төн газапланды, ахыр чиктә взвод командиры белән аңлашырга булды. «Эти карт килгән иде, Иона Владимирович, – диде ул, тавышына йомшаклык бөркеп, – авылдан. Чирли гел! Аяк-куллары сызлаулы, бил өянәге кузгалса, атналап ахылдап ята икән. Беләкләренә тимрәү чыккан. Авылыбызда больница юк, бер әпчи карчык бар барын... «Коммунист атасы әпчи карчыкларга йөрергә тиеш түгел. Чакыр. Килсен. Больницага салырбыз», - дип күтәреп алды командир. «Карт сөякне дәвалап кына рәткә кертеп булыр микән? Аны караштырып, иплэштереп торырга иде!» – диде Мостафа командирына беренче тапкыр каршы төшеп. «Казанга, үз яныма алдырам мин аларны!» «Ә фатир?» – диде командир, иренен тешләп. «Ул ягын үзем карыйм!» – диде Мостафа, потлы йодрыгы белән һаваны телеп.

Булды, «картларны ни уйлап урыннан кубардың?» дип, кызыксынучылар булды. Читләргә түгел, үз-үзенә дә Мостафа өзеп кенә җавап бирә алмады. Сүзен сүз итәсе килдеме, әллә бүтән бер сәбәбе бар идеме? Ничек дияргә, ничек аңлатырга? Тома ялгызлыкның авырлыгын тоя башлаган мәле идеме бу аның? Телне көне-төне йозакта тотарга гадәтләнеп, хәзерендә кемгәдер сыенып, чәнти бармак хәтле генә булса да күңелен ачып, бушанырга, баш миен тыгызлаган язмыш басымын җиңеләйтергә ашкынган чагы булдымы? Боларга туры җавап табар өчен җанына үзе хуҗа булу кирәк иде, әмма соңгы вакытларда Мостафаның җанына да, тәненә дә бүтән хуҗалар табылган иде, усал, кансыз, ерткыч хуҗалар.

Хатын-кыз ире хакында берни дә белмичә яши алмый, ул нидер белергә, белгәннәренә таянырга тиеш. Ирең еш-еш кына бик соң, кайчагында таң беленгәндә, хәтта ки таң яралганда урынга кайтып шым гына кереп ята икән, эшләр хәтәр якка кереп китте дигән сүз. Моны аңлау өчен зур акыл кирәкми, ир тормышы хатыны күз алдында үтә. Халисә Мостафаның фотосын алып Суконный базары тирәсендәге күрәзәчегә барды. Ватык патефон тәрилкәседәй туктаусыз выжлап утырган чәчрәп торган чандыр карчык сурәткә күз салуга тынды, «әстәгъфирулла!» дип бер пышылдады да, аскы бүлтәйгән коры иренен вак-вак тешләре белән тешләп, күзләрен шакрайтып ачып, хәтсез ара сүзсез карап торды. Халисә күзләрен күтәреп карарга базмады, җәенке борынлы шадра тел бистәсенең куллары калтыранганын күреп каушап, агарынып калды. Күрәзәченең адресын биргән белеш хатын: «Җентекләп сораша башласа саграк кылан, ул шулай сиздермичә генә сине чишендерә, сереңне ала!» – дип кат-кат кисәтеп җибәргән иде, хак булмады, шадраның авызыннан ник бер сынык сорау кисәге өзелсен! Бераздан шадраның кысылган иреннәре язылды, янычелеп, имгәнеп, аңлашыр-аңлашылмас сүзләр идәнгә коелды. «Өгәренки бу адәм ирең икән, әйтәм, бик хәтәр хезмәттә икән ул, балакаем, авыр эштә! Әйтерлек тә түгел, менәкәччәем, тәмуг капкасында сакта тора диярлек. Җук, кәнтәйләр белән йөрми, хатыннар белән аралашмый. Хезмәте яман, жалуниясе мул чыкса да, авыр эштә! Исән кала икән, анысы Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән генә булыр. Бүтәнен әйтә алмыйм, апаем. Әйтергә дә кушмыйлар». Халисәнең инәлеп: «Нигә алайса гел-гел төнлә эшләтәләр аны? Отпускыга чыкса да чакырып алалар?» – дип сорыйсы килде, теле кычытты, тәненә тир йөгерде. Күрәзәченең куркыны сүзләреннән соң мондый сорау вак-төяк булып калды да, артыгын сорашырга базмады Халисә, төпченеп тормады.

Инде күрәзә дә иренең серен тәмам ачып бетерә алмагач... эшләр мөшкел икән!

Халисә Мостафаны элеккечә елмаеп-көлеп каршы алды, сөеп-сөенеп озатты, «нигә алай соңарып кайттың?» дип бимазаламады, бер ягы үзгәрде: ул иренең һәр хәрәкәтен, ымын, ишарәләрен, аяк атлауларын, хәтта ки пешкән бәрәңгене ничегрәк чәйнәүләрен кызыксынып, берәмтекләп күзәтә, хәтер сандыгына вакчылланып җыярга тотынды. Белер иренең кемлеген Халисә, боерган булса – белми калмас.

Мостафа бәрәңгене тешләп тормый, күсәгәсе белән каба, теле белән аңкавына терәп сыта да йота икән. Чәй йомрысын авыз турына күтәргәч, төшереп тормый, голт итеп йотып җибәрә. Кайнармы чәе, талгынмы, һич исәпләп утырмый! Йокысыннан уянгач, ике кулы белән күз чокырына баса, күз алмалары ышырдап, тавыш бирәләр... Боларны җыеп-уйлап, бер-бер нәтиҗә чыгарырга тырышса да, хатын ире хакында берни дә белә алмады, Мостафа баш астына мендәр салмый башлагач кына, аптырашта калды.

Кайнатасы шәһәргә күчеп килгәч, ярты еллар чамасы улында торып торды, аннары: «Хәлебез барында үз куышыбызны карыйк!» – дип, шул ук урамның аргы башыннан йорт-җир алып, шуны

иплэп-сиплэп аерым-аерым яши башладылар. Еш булмаса да, картлар аларга килгәләп йөри, Халисә дә бара, малайлар бабаларыннан кайтмыйлар да диярлек иде, йоклап та калалар. Мостафаның гына барырга вакыты табылмый, төнлә эштә, көндезләрен йокыда.

Кайнатасы белән кайнанасы беркөн Суконный базарыннан кайтышлый чәйгә кереп чыктылар. Кыстыбый пешергән иде Халисә. Кыстыбые тәмле, куе чәй зиһеннәрне ача, Халисә сүз арасына: «Мостафага мендәр дә кирәк булмый башлады», – дип кыстырып куйды. Бианасы: «И килен, бала чактан шулай инде ул, ятыр иде, уянганда мендәре бер читтә, ә башы как идәндә булыр ие», – дип сайрый башлаган гына иде, карт кул ишарәсе белән аның сүз ташкынын кисте. «Кайгы-хәсрәте зур икән улымның!» – дип, башын як-якка чайкап утырды. Шушы сүз соңы белән Халисәнең болай да янып-көйрәп яткан күңеленә ут өстәде.

Мостафасы эшеннән вак-төяк әйбер-кара, кием-салым алып кайтып йөри башлагач, Халисә ифрат сөенде, соңыннан курка, шикләнә башлады. Очы-очы белән ситсалар, киелмәгән күлмәк-чалбарлар кайтты. Арада гел кирәкмәгәннәре дә бар иде. Андыйларны Халисә Мостафага әйтмичә генә базарга шудырды, хатын-кызга акча бер чакта да җитми. Суконныйның якынлыгыннан рәхәтләнделәр. «Эштән бирделәр», – ди Мостафасы. Эштән тек эштән, мал бераүгә дә күктән ямый, ахыр чик, аның Мостафасының кулы озын түгел, урлашмас, биргәннәр икән – ник алмаска. Үзләреннән артык-портык күренсә, кайната белән кайнана да алагаем мул яшәмиләр, сөлге-тастымалга да хаҗәт чак. Аларга да өлеш чыгара юмарт килен! Балалар үсә, аларга да кием җиткезер хәл юк, язын кигән көзгә курачланып, утырып кала. Халисә җәй аралаш үзенекеләргә Сабан туена кайтмый калмый. Бүләк-санаксыз авыл-көн алдында ничек күренәсең? Сабан туе якынлашса, Халисә дә ир колагы ишетерлек итеп сайрый: «Теге буй-буй күлмәгем бәләкәйләнгән, Миңсылуга алып кайтсам ничек булыр икән?» – дип кабатлый. Мостафа дәшми, күз чите белән генә ризалыгын белдереп елмайгандай итә.

Төннәрнең берсендә, шомлы җиллесендә Мостафа бик матур жакет алып кайтты. Елык-елык итеп күз явын алып тора. Бер дә бәяләп бетергесез. Кайтты да хатынының иңенә салды. Күзе яман елтырый! Тагын тамагын чылаткан дигән сүз! Халисәне өр-яңа, иделнән түшәмгә сузылган дәү көзге каршысына бастырды Мостафа. Әнекәйгенәм, үзенә үлчәп теккән диярсең, Халисәнең иренеп кенә ачылган күзе шар булды. Тик ире жакет белән туйганчы куанырга ирек бирмәде, буар еландай Халисәнең биленнән урап тотты да, каз кауры сыман очыртып, суынып өлгермәгән караватка алып китте.

Иртән кем беләндер балыкка барырга килешенеп кайткан икән, кайнатып куйган сөтне кәстрүлен күтәреп эчте дә чыгып югалды Мостафа. «Сау бул», – димәде, дәшмәде. Хатын жакетны киеп, сыйпаштырып, үзенең өч бала тапса да зифалыгы үзгәрмәгән гәүдәсеннән канәгатьлек хасил кылып, күгелҗем күз тирәләренә кунган чык бөртекләрен сөртим дип, искәрмәстән кесәсенә кулын тыкса, аннан дүрткә бөкләнгән кәгазь килеп чыкты. Сүтеп ачса – хат! Кулы хатын-кызныкы, хушбуй исе килеп киткәндәй булды. Укып-укып карады Халисә, зиһене түнгән иде, башта берни аңламады. Иҗекләп, уйлый-уйлый, һәр ноктага, өтергә туктала-туктала, шактый утыргач кына нидер төшенгәндәй булды. Барыбер аңлап бетермәде. Күңеленә иңгән ят шом көне буе аңа тынгылык бирмәде.

«Варис, – диелгән иде ашыгыч язылган хатта. – Кичә таң белән бәләкәй абзыйны алып киттеләр. Черек күлгә инде, бүтән кая булсын. Чибәр апа да нык курка, мөгаен, аны да йомдырырлар. Бусаганы атлап бер керсә, тиз генә чыгарып җибәреп булмый диләр хәзерге заман үләтен. Итәгеңне җыеп, телеңне тыеп йөр берүк. Чибәр апаны да кулга алсалар, мин нишләрмен?!»

Чик-чамасыз китмәс сораулар кузгатты Халисә күңелендә бу серле хат. Эшендәге кибеттән сатып алынган жакет кесәсенә ничек килеп кергән ул? Кем язган, кемгә адресланган? Җибәргән иясенә барып җиткәнме?

Мостафа, гадәтенчә, бармак башы хәтле өч кәрәкәдән башка бер юньле балык та тота алмаган, дөресен әйткәндә, махмырдан һәм йокысызлыктан җәфаланып, яр буенда аунап вакытын үткәргән иде. Иллә мәгәр карыны ачкан, ач бүрегә әйләнгән. Өч тәлинкә куе, өреле шулпаны әйләндереп кенә каплады. Чиле-пешле күкәйләрне бер кабуда йотты. Сөякле итне күсәгәсе белән тотып нык, таза тешләрен иткә батырды. Бүтән чакларда Халисә иренең шулай ясканып ашаганын, ул пешергән ризыкларны яратуын күзәтеп торып, сөенеп бетә алмый иде. Бүген бер читтәрәк йомылып утырды, сүз кушарга да базмады.

Белә, тамагы ач ирнең камчысы диварда гына эленгән була.

(Дәвамы киләсе санда.)

(Дәвамы. Башы 22 нче санда).

Венгр галиме Х.Паксой да Чураның үлеме әсәрдә үтә үткер һәм кинаяле-символик итеп тасвирлануына дөрес бәя бирә: «Марҗа кызы белән бәйләнү сәбәпле, ул үз үлемен таба, ә бит моны бер генә батыр да, хәтта бернинди гаскәр дә эшли алмас иде», – дип яза. Дастанда Казанны саклауның барып чыкмавына һәм ике арадагы сугышның күп корбаннарга китерүенә сәбәп булган башка төрле кимчелек-хаталарга да ишарәләр бар. Беренчедән, бу – Казанны дошманнан саклау белән Кырымнан килгән каһарман гына диярлек шөгыльләнгән итеп тасвирлануы, пайтәхеттә яшәүче морза-бәкләрнең исә, капма-каршы төркемнәргә бүленеп, ил язмышын кыл өстендә калдыруы. Өстәвенә бер-бер артлы алышынып торучы кайбер ханнарның – Мәскәү марионеткаларының чит баскынчылар ягын каеруы. Әсәрнең нугай вариантында, Казанга килгәч, Чура авызыннан әйтелгән сүзләр нәкъ менә татарлар арасында бердәмлек булмавын раслап тора:

Халык әйткән хак икән,
Айсыз икән ханыгыз.
Бу Казанның ханы бар да,
намы юк.
Казые бар, түрә юк.

Дастанның берничә планлы яки күпкырлы сәяси-идеяле рухы, эчтәлеге урыны-урыны белән, чыннан да, теге яки бу чорның рухи атмосферасы һәм тарихи реалийлары белән яраша. Алда әйтелгәнчә, әсәрнең бер нугай вариантында, мәсәлән, баскынчы русларга каршы торучы Казан ханының исеме Гәрәй дип, кырымтатар вариантында Сафа дип күрсәтелә. Бу хан Казан тәхетендә берничә мәртәбә утырган Гәрәйләр династиясе дигән Кырым ханнарының берсе буларак кабул ителүне сорап тора. Җөмләдән, 1521 елда Кырым фирка-төркеме тарафыннан ханлык башына мендерелгән Сәхибгәрәй хан, килү белән үк, җавап рәвешендә Мәскәүгә һөҗүм ясый һәм ике елдан, руслар яклы Хөсәен ханны куып, Әстерханны яулап ала. Шуннан соң тәхеткә утырган Сафагәрәй дә абыйсының сәясәтен дәвам итә һәм өч мәртәбә хан булып тору дәверендә Мәскәү төркемен бик нык эзәрлекли, руслар һөҗүмен кире кайтарганнан соң, Мәскәүгә үзе яу белән бара. Мондый кара-каршы яулар берничә мәртәбә кабатлана һәм басым ясап әйтергә кирәк: руслар ягыннан бу сугышлар яулап алу, буйсындыру максатын күздә тотса, татар яулары башлыча җавап рәвешендә һәм талау, мал үзләштерү характерында була.

Югарыда әйтелгән тарихи хакыйкатьне объектив карашлы рус галимнәре дә таный. В.Похлёбкин, мәсәлән, болай дип яза: «Казан ханлыгы Мәскәү дәүләтенә караганда чагыштырмача һәм формаль яктан ныграк тынычлык яклы була. Ул беркайчан да күрәләтә кыдрачланмый. Ханлыкның Мәскәүгә кагылышлы бернинди яулап алу планнары да булмый. Казан яуларының күпчелеге йә русларның басып керүләренә каршы юнәлдерелгән кирәкле саклык чаралары төсендә, йә булмаса, аңа кадәр ясалган рус һөҗүмнәренә гадәти җавап рәвешендә оештырыла». (В.В.Похлебкин. Татары и Русь. – М.,2005. С.108,113).

Марсель БАКИРОВ

«Чура батыр» дастаны

Казан ханлыгында Сәет, дин башлыгы булган Шәрифинең «Зафәрнамәи вилаяти Казан» дигән тарихи-публицистик язмасында Иван IV нең 1550 елда Казанны алырга дип килгән яуларына каршы татар гаскәренең батырларча сугышуы һәм шәһәрне саклап калуы тасвирлана. Зур батырлык күрсәткән һәм исемнәре аталган каһарманнар арасында автор беренчеләрдән итеп Сафагәрәй ханны күрсәтә, «Сафагәрәй – баһадир хан», «Әгәр җәфалаучылардан үч алмасам, үзем җәфаланучыга әйләнермен, дип әйтеп, үзенең сугышчан атын иярләп, биленә дошманнарны кыра торган зиннәтле кылычын тагып, ислам дине өчен сугыш юлына басты», – дип яза.

Рус империячел дәүләтенең, Казанны алу белән үк, татарларны көчләп чукындыру һәм йоту-ассимиляцияләү сәясәтенә күчүен исәпкә алганда һәм ханлыкны корал белән буйсындырганда ук шул максат күздә тотылуына игътибар иткәндә, ислам диненең элек-электән үк татар халкын берләштерә торган һәм этнос-милләт буларак юкка чыгудан саклый торган фактор булганлыгы шиксез. Шуңа күрә дә бер үк дин тоткан һәм хәтта үзара якын-кардәш телдә сөйләшкән кырымлыларның Казанның һәм ханлыкның мөстәкыйльлеген саклауда билгеле бер өлеш керткәнлеге, шул исәптән эпос-дастанда да Чураның Кырымнан килгән батыр итеп тасвирлануы аңлашыла.

Инде урынлы сорау туа: кем булган соң ул Чура батыр, аның конкрет прототибы булганмы? Фольклорчыларның һәм тарихчыларның кайберләре (мәсәлән, Ф.Урманчеев, Л.Ибраһимова) бу сорауга уңай җавап бирә һәм әлеге каһарманга өлге-прототип ролен үтәгән шәхес Казан аксөяк-бәге Чура Нарыков булган дигән караштa тора, хәтта һәр төрки милли вариантларына да шул шәхес өлге итеп алынган дип исәпли. Моның өчен, әлбәттә, Чура Нарыковның рус елъязмаларында теркәлгән исем-фамилиясе, ягъни үзенең һәм атасының исеме дастандагы Чура һәм Нарәң (Нарык) исемнәре белән тәңгәл килүе нигез һәм дәлил итеп алына, хәтта тюрколог В.Жирмунский да заманында шул ук алдавыч кармакка эләгә. Шуңа бәйле рәвештә Чура Нарыковның сәяси-иҗтимагый эшчәнлегендәге тискәре яклар да – татар авторлары тарафыннан тартып-сузулар һәм шомарту-йомшартулар исәбенә – Казан ханлыгын саклап калу һәм яшәтү хакына эшләнгән кирәкле гамәлләр итеп күрсәтергә яки исбатларга тырышыла.

Асылда, Чура Нарыковның, Мәскәү мәнфәгатен яклап, Сафагәрәй белән Сөембикәгә һәм аларның ханлык мөстәкыйльлеген саклау сәясәтенә каршы юнәлдерелгән хыянәтчел эшләрен аклау мөмкин түгелдер. Аерым алганда, ул – Казан өстенә яу-гаскәр җибәрүләрен сорап, Мәскәүгә ике тапкыр илчеләр җибәргән һәм кырымлыларның барысын да, Сафагәрәй ханны да кертеп, руслар кулына әсирлеккә тотып бирергә вәгъдә биргән кеше. Шулай ук Шаһгалигә «тәлинкә тотып», әлеге ташка үлчим ханның юк абруен сакларга тырышып йөргән «олы морза» һәм, хәле мөшкелләнгәч, аңа Казаннан качып китәргә ярдәм иткән «зур сәяси фигура» да – ул. Казан ханлыгы мәнфәгатьләре өчен «тырышканлыгын» раслап, Чура Нарыков хәтта үзе дә гаиләсе, яраннары һәм мең кешелек сакчылары белән соңыннан Мәскәүгә качып китә, әмма юлда хан гаскәре тарафыннан куып җитеп үтерелә. Тарихи чыганакларда шулай ук Чураның 1547 елда Мәскәү яклы морзалар белән бергә Сафагәрәй хан тарафыннан җәзалап үтерелүе турында да мәгълүмат сакланган.

Рус чыганакларыннан билгеле булганча, «рус хөкүмәте Кырым фирка-төркеменә каршы морза-бәкләрне ачыклау һәм, алтын, мех, төрле кыйммәтле бүләкләр биреп, системалы рәвештә аларны «сатып алу» белән шөгыльләнә. Шулай ук килешү турында сөйләшүләрдә катнашучы барлык илчеләр дә юл бүләге бирү сылтавы белән «сатып алына». Менә шундый чаралар ярдәмендә Иван IV нең татар агент-шымчылары Сафагәрәйне бәреп төшерү һәм аның урынына рус кандидатурасын – Шаһгалине хан итеп утырту өчен сарай түнтәрелеше әзерли». Табигый ки, Чура Нарыков ошбу фетнә-түнтәрелешне әзерләү һәм оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе була. Димәк, аның кабат тәхеткә утырган Сафагәрәй тарафыннан нәкъ шуның аркасында үлем җәзасына тартылуы турында сакланган мәгълүмат нәкъ шуның белән бәйләнгән булырга тиеш.

Дастандагы ата һәм ул исемнәре белән Казандагы әле генә күздән кичергән хыянәтче бәкнең исем-фамилиясе туры килүенә карап кына аларны үзара тиңләштерү, икенчесе беренчесенең прототибы булгандыр дип карау, безнеңчә, дөреслектән шактый ерак тора. (Белүебезчә, төрле кешеләрнең, шул исәптән күренекле шәхесләрнең исем-фамилияләре һәм аталарының исеме үзара тәңгәл килү бүгенге көндә дә еш очрый бит!) Шушы ясалма схемага ярашып, әлеге кире-тискәре тип булган Чура Нарыковтан, имеш, ул үзен куып җиткән хан гаскәре – димәк, үз иле яугирләре белән «тиңсез сугыш-бәрелештә, нәкъ менә халык дастаннарындагыча, батырларча һәлак була» (Ф.Урманчеев) дип герой-каһарман ясарга тырышу да гаҗәп дәрәҗәдә урынсыз. Шулай ук әлеге «Казан морзасының тарихи эшчәнлеге белән» аның дастани язмышының үзара туры килмәвен «тарихи эпос әсәрләре һәм тарихи вакыйгаларның еш кына үзара каршылыкка керүе» дип аңлату да, шулай ук «әсәрнең тәэсир көчен арттыру ихтыяҗы» белән бәйләү дә бу очракта һич аклана алмый.

Чура Нарыковның сатлык җан икәнлеген халык, һичшиксез, белгән һәм аны өнәмәгән, хәтта күралмаган булырга тиеш. Менә шуңа күрә дә башкортларда «Сура (Чура) батырның рус гаскәрләренә ярдәмгә баруы» дип исемләнгән тарихи риваять сакланып калганлыгына һич тә гаҗәпләнергә кирәкми. Анда кат-кат һөҗүм итеп тә Казан каласын ала алмаган рус гаскәренә нәкъ менә Чураның ярдәмгә килүе һәм, төнлә халык йоклап беткәч, дошманга яшерен керү һәм чыгу юлларын күрсәтеп, шәһәрне алырга ярдәм итүе турында сөйләнелә. Ошбу риваятьтә тасвирланган Чура белән русларны үз халкы өстенә яу белән килергә чакырып яткан Чура Нарыков арасында шактый охшашлык булуы шиксез. Шулай ук Яшел Үзән районының Карауҗа (Кара Хуҗа) авылында тарихчы-археограф М.Әхмәтҗанов тарафыннан язып алынган ярым легенда характерындагы тарихи риваятьтә дә Чура би Казан ханлыгына хыянәт иткән итеп, ягъни Мәскәү патшалыгына серләрне саткан кеше буларак күрсәтелә. Шуның өчен хан аны, «байлык җитми иде сиңа, мә, ал» дип авызына эретелгән көмеш коеп үтергән диелә «Карауҗа» исемле әлеге риваятьтә. Кыскасы, халык иҗатының аерым үрнәкләрендә Чура батыр образы белән сатлык җан Чура бәк шәхесе бер-берсенә капма-каршы куеп тасвирлана.

Бәлки, чичән-җыраулар икейөзле Чура Нарыков бәкне дә дастанга, марионетка Шаһгали хан кебек үк, юри гыйбрәт итеп һәм Чура, асылда, дошманга каршы үзләре тасвирлаган батыр шикелле көрәшергә тиеш иде дип керткәннәрдер? Болай уйларга нигез юк. Чөнки халык иҗатында Чураны дастандагы кебек идеаллаштырган һәм нәкъ менә мөдһиш Иванга, аның яуларына каршы сугышучы пәһлеван итеп тасвирлаган борынгы җырлар һәм бәетләр дә бар. Аларның берсе, К.Насыйриның 1880 елгы календарьда басылып чыккан «Казан бәете» исемендәгесе, Чура батырны ни рәвешле тасвирлавы ягыннан борынгы казах тарихи җыры белән аваздаш.

(Дәвамы киләсе санда).

● Алдынгы хуҗалык җитәкчеләрен Сабан туе мәйданында каршылау.

● Җитәкчеләр һәм кунаклар хуҗалыклар төзеп куйган аерым йортлар янында.

ТҮБӘТӘЙЛЕ, АТЛЫ,

(Актаныш район Сабан туеннан фоторепортаж)

● Юртаклар ярышы.

● Чабышкы атлар бәйгесе.

● Зәйдән килгән осталарның конкур чыгышы.

● Кул арбасына кызлар утыртып узышу бәйгесендә җиңүче парлар.



● Сабан туеның иң көчле кешесен ачыклау.

● Милли көрәш малай чактан башлана.

● Сәнгать әһелләре чыгышы.

● Алдынгы савымчыларны бүләкләү.

ЗАТЛЫ ТУЙ

Вахит ИМАМОВ фотолары.

● Капчык киеп узышу.

● Сабан туе кунаклары.

● Суга чумып тере балык тоту.

● Резина бау тарткан көе бүләк эләктерү читен.

● Яшьләр арасында көрәштә җиңүчегә 73 кг лы тәкә.

● Сабан туеның абсолют батыры Азат Габдерәшитов 83 кг лы тәкә яулады.

Каһарман

1944 елның 25 февралендә «Кызыл Татарстан» газетасында (№39) Мәрьям Дибаеваның «Сәет абзый уллары» дигән мәкаләсе басыла. Анда Казан сөт заводында эшләүче Галия һәм Татар радиокомитетында механик булып хезмәт куючы Сәетнең уллары Шамил белән Равилнең Бөек Ватан сугышында батырлыклары тасвирлана. Томск каласында яшәгән гаилә 1920 елда – өлкән уллары, тагын өч елдан төпчекләре тугач, татар иле башкаласына күченеп кайта. Ике уллары да кечкенәдән үк хәрби булырга хыялллана: Шамил Казанның – 6 нчы, Равил 24 нче урта мәктәпләрен тәмамлап, Мәскәүдәге артиллерия һәм Чкалов каласындагы (Оренбург) зенит училищеларына укырга керә. Ике яшь офицер сугышны алгы сызыкта каршылый. Лейтенант Шамил Рәхмәтуллин әүвәл 61 нче укчы корпус составындагы 438 нче корпус артиллериясе полкында (438 нче җиңел артиллерия полкы белән бутарга ярамый) взвод командиры. 20 нче армия составында Ставка резервында торган полкны 24 июньдә яу кырына кертәләр, 7 июльдән ул Көнбатыш фронттагы 13 нче армиянең 61 нче укчы корпусын көчәйтә.

● Шамил Рәхмәтуллин.

Сугышның беренче көннәреннән үк Көнбатыш фронтта хәлләр тәмам җәһәннәмгә әйләнә. 22 июньнән 8 июльгә чаклы дәвам иткән Белосток-Минск орышларында фронтның күпчелек көчләре камалышта кала һәм тар-мар ителә, ягъни 625 мең кешенең 420 меңе бөтенләйгә сафтан чыга, зур күләмдә хәрби техника дошман кулына эләгә. Күнегелгән гадәт буенча, СССР халык оборона комиссары И.В.Сталин бөтен гаепне командование өстенә өя: 30 июньдә фронт командующие Советлар Союзы Герое армия генералы Дмитрий Павлов вазифасыннан бушатыла һәм 4 июльдә кулга алына, кыска вакытка сузылган тикшерү барышыннан соң аны 22 июльдә атып үтерәләр. Дмитрий Григорьевич белән бер көнне якты дөнья белән хушлашучылар: фронтның штаб башлыгы генерал-майор Владимир Климовских, элемтә башлыгы генерал-майор Андрей Григорьев һәм 4 нче армия командующие Александр Коробков. Фронтның артиллерия башлыгы генерал-лейтенант Н.А.Клич белән 14 нче механикалаштырылган корпус командиры генерал-майор С.И.Оборинны да шундый ук ачы язмыш көтә: аларны 8 июльдә кулга алалар һәм тиз арада бакыйлыкка күчерәләр. Ә менә фронтның Хәрби совет әгъзалары корпус комиссары званиесендәге Александр Фоминых белән Пантелеймон Пономаренко үлем хөкеменнән котылып кала: Александр Яковлевичның званиесен полк комиссарына төшерәләр һәм ул 124 нче укчы дивизиянең хәрби комиссары вазифасына керешә, Пантелеймон Кондратьевич исә Үзәк фронтта шул ук вазифада хезмәтен дәвам итә.

30 июньдә фронтның яңа командующие итеп генерал-лейтенант А.И.Еременко билгеләнә, бер көннән штаб башлыгы вазифасына – генерал-лейтенант Г.К.Маландинны, тагын ике көннән Хәрби совет әгъзасы итеп 1 нче рангтагы армия комиссары Л.З.Мехлисны куялар. 2 июльдә фронтның яңа командующие вазифасында – Советлар Союзы Маршалы С.К.Тимошенко, ә Еременко аның урынбасары булып кала. Бер үк вакытта Семен Константинович 10 июльдән фронт составына резервтагы армияләрне кушу нәтиҗәсендә оешкан Көнбатыш стратегик юнәлештәге гаскәрләрнең Башкомандующие вазифасын да башкара. Татарстанның хәзерге Чирмешән районына кергән, нигездә чувашлар яшәгән Иске Әлмәле авылында туган генерал-майор Федор Бакунин командалык иткән 61 нче укчы корпусның сакланып калган аз санлы көчләре 23 июль төнендә өч колоннага бүленеп камалыштан чыгарга омтылыш ясый, әмма бу адым уңышсыз тәмамлана. Ике көн дәвам иткән сугышлар вакытында корпус составындагы дивизияләр тулысынча тар-мар ителә, генерал Бакунин исә бөтен техниканы юк итәргә, атларны куып таратырга һәм вак төркемнәргә бүленеп камалыштан чыгарга боерык бирә. 140 хәрбидән торган төркемне үзебезнең гаскәрләр янына алып чыккач, Федор Бакунин фронтның хәрби советы карамагында була, декабрь аеннан ул – М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә өлкән укытучы һәм курслар башлыгы...

3 август төнендә 438 нче артиллерия полкының 270 сугышчысы һәм командирлар составындагы 50 кеше Васьковичи тирәсендә камалыштан чыга. Гомумән алганда, бу әүвәл 1536 яугирдән торган полк составының биштән бер өлеше генә: калганнары һәлак була, әсирлеккә эләгә яисә хәбәрсез югала. Кайбер хәрби чыганакларда милләттәшебез лейтенант Шамил Рәхмәтуллин да хәбәрсез югалганнар исемлегендә күрсәтелә, әмма бу дөреслеккә туры килми. Аяныч, хәрби архивта сакланган һәм төгәл документлардан саналган исәпкә кую карточкасында да кайбер төгәлсезлекләр күзгә ташлана. Аннан күренгәнчә, ул 1 нче Мәскәү артиллерия училищесын тәмамлагач, 1941 елның июнь аенда 248 нче корпус артиллериясе полкының 3 дивизионында – разведка командиры, августта 64 нче укчы дивизия составындагы 219 нчы гаубица артиллериясе полкында – идарә взводы командиры, ә инде 26 декабрьдә 112 нче кавалерия дивизиясенең 275 нче полкында батарея командиры вазифасында. Әлбәттә, аның 438 нче корпус артиллериясе полкында хезмәт итүе күрсәтелмәү – документларны тутыручы штаб хезмәткәренең ваемсызлыгы нәтиҗәсе. Чөнки лейтенант Шамил Рәхмәтуллин нәкъ шул полкта хезмәт иткәндә, 1941 елның 9 августында Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Туктаусыз чигенгән, дивизияләр, корпуслар һәм армияләр камалышта калган чагында иң дәрәҗәле орденнарның берсенә лаек булу өчен, бик тә зур батырлыклар кылу кирәклеге шик уятмый. 30 августта Көнбатыш юнәлеше гаскәрләре Башкомандующие Советлар Союзы Маршалы Семен Тимошенко белән Хәрби совет әгъзасы Николай Булганин үз хәрбиләрен югары хөкүмәт бүләкләренә тәкъдим итү исемлегенә кул куя. Исемлектәге Кызыл Байрак орденына тәкъдим ителгән лейтенант Рәхмәтуллинның 61 нче укчы корпус составындагы 438 нче корпус артиллериясе полкында взвод командиры булып хезмәт итүе ташка басылган. 9 август көнендә үк каһарманнарның хөкүмәт бүләкләренә лаек икәнлеген раслап, СССР Югары Советы Президиумы рәисе Михаил Калинин имзалаган Указ дөнья күрә.

Декабрь аенда милләт баласын тылга озаталар һәм Ставка карары белән оеша гына башлаган 112 нче Башкорт кавалерия дивизиясенең (1943 елның февраленнән – 16 нчы гвардия кавалерия дивизиясе) 275 нче кавалерия полкына (1943 елның февраленнән – 58 нче гвардия кавалерия полкы) батарея командиры итеп куялар. Хәзер Уфа ягы никадәр генә яшереп сакларга тырышмасын, шунысы хак: Шамил Рәхмәтуллин – әлеге дивизиягә җәлеп ителгән бик күп татар командирларының берсе. Полк батареясын ул үзе оештыра һәм яуга әзерли. Дивизия 1942 елның җәендә Брянск фронтының 8 нче кавалерия корпусы составында сугышка керә һәм Воронежны азат итү өчен оештырылган һөҗүм операциясендә, Сталинградны саклау өчен җәелдерелгән аяусыз бәрелешләрдә катнаша. Каһарман милләттәшебезнең батырлыгы, кискен хәлләр туганда каушап калмавы, үз батареясы белән оста идарә итүе турында генерал Шәйморатов һәлак булганнан соң сугыш тәмамланганчы 16 нчы гвардия кавалерия дивизиясе белән командалык иткән генерал-лейтенант Григорий Белов үз истәлекләрендә түбәндәгечә бәян итә:

«Бу сугышта 275 нче полкның өлкән лейтенант Ш.С.Рәхмәтуллин командалык иткән полк батареясы бик яхшы эшләде. Үзенең ут ачу позицияләрен ул эскадроннарның хәрби сафларына якынрак урнаштырды... Рәхмәтуллинга дошманның танк атакасын беренче тапкыр кире кагу нәкъ менә Дон далаларында туры килде... Дошманның 10 танкы полкның уң флангын әйләнеп үтә башлады. Алар берничә минут эчендә хәрби сафларны өзгән булыр иде, әмма Ш.С.Рәхмәтуллин аларның максатын сизеп алды һәм танкларның бортларына ату өчен тупларны 90 градуска борырга боерды...

Батарея командиры бинокле ярдәмендә үз артиллеристларына кая атарга кирәклеген әйтеп торды. Аның салкын канлылыгы, каушап калмавы яугирләрен дә тынычландырды, һәм алар бөтен боерыкларны автомат тизлегендә башкара башлады. Әлбәттә, бу Ш.С.Рәхмәтуллин тарафыннан үз батареясын хәрби яктан әзерләүдә башкарылган олы хезмәт нәтиҗәсе иде» (45 – 46 б.).

Бу Сталинградны азат итү өчен башланып киткән операциянең дүртенче көнендә Обливск тимер юл станциясен басып алу өчен оештырылган һөҗүм барышы белән бәйле бер генә мизгел. Шунысы бар, өлкән лейтенант Рәхмәтуллинны «башкорт» буларак тасвирлаган Белов бу орыш вакытындагы бер мөһим вакыйганы йомып калдырган. Каһарман турында язучы Л.Ханинның «Безнең якташлар – Советлар Союзы Геройлары» китабындагы мәкаләсенә мөрәҗәгать итик: «Станция өчен сугыш ике көн дәвам итә. Дошманның кабатланып торган контрһөҗүмнәрен кире какканда артиллеристлар ике танкны яндыра, берничә пулеметны һәм тупны сафтан чыгара. Каты бәрелешләр вакытында полк командиры һәм аның урынбасары яралана. Шул кискен мизгелдә Рәхмәтуллин үзе полк белән командалык итә башлый һәм подразделениеләрне атакага күтәрә. Нәтиҗәдә фашистларны станциядән бәреп чыгаралар» (222 б.).

Тагын бер хәрби чыганак.

Рәхмәтуллиннар

● Равил Рәхмәтуллин.

1942 ел тәмамланып килгәндә, Воронеж фронтында сугышканда капитан званиесенә үрләтелгән Шамил Рәхмәтуллин яңа елның 6 февралендә I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. Гәрчә 245 нче кавалерия полкы командиры капитан Идрисов белән штаб башлыгы капитан Әюпов 16 гыйнвар көнне полк батареясы командирын Кызыл Байрак орденына тәкъдим итеп тутырылган бүләкләү документын имзалаган була. Аларның тәкъдимен 112 нче кавалерия дивизиясе командиры генерал-майор Шәйморатов белән 8 нче кавалерия корпусы командиры генерал-майор Борисов та яклап чыга. Әмма 5 нче танк армиясе Хәрби советында капитан Рәхмәтуллинны күпкә түбәнрәк дәрәҗәдә йөрүче I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләргә карар кылына. Үз армиясе хәрбиләрен орденнар белән бүләкләү турындагы ышерен Боерык чыккан көн – 1943 елның 6 феврале, Боерыкны имзалаучылар – армия командующие генерал-майор Иван Шлемин, Хәрби совет әгъзасы генерал-майор Гай Туманян һәм штаб башлыгы генерал-майор Алексей Данилов. Бүләкләү документында капитан Рәхмәтуллинның үзен кыю, куркy белмәс, тәвәккәл командир итеп танытуы ассызыклана. Аның җитәкчелегендәге батарея 19 ноябрьдән алып дошманның 9 танкын, 7 автомашинасын, 3 тубын, 16 пулеметын, 3 күзәтү пунктын сафтан чыгара, 200 гә якын офицерны һәм солдатны юк итә. 1942 елның 1 декабрендә полк командиры сафтан чыккач, командованиене үз кулына ала һәм һөҗүмне дәвам иттерә. 1943 елның 24 мартыннан Шамил Рәхмәтуллин 16 нчы гвардия кавалерия дивизиясе составындагы 148 нче гвардия артиллерия-миномет полкы командирының урынбасары итеп билгеләнә, 10 сентябрьдән – 16 нчы гвардия кавалерия дивизиясе артиллериясының штаб башлыгы. Милләттәшебезнең карьера үсеше башны әйләндерерлек, тагын 11 көннән ул инде 14 нче гвардия кавалерия дивизиясе составындагы 146 нчы гвардия артиллерия-миномет полкы командиры. Кызганыч, бу вазифасында озак хезмәт итәргә язмый: 1 октябрьдә Днепрның уң ягындагы плацдармны саклап калу өчен барган аяусыз алышлар вакытында батырларча һәлак була.

Шул яуда кылган батырлыклары өчен Үзәк фронтның 7нче гвардия кавалерия корпусы составындагы 14 нче гвардия кавалерия дивизиясенең 146нчы гвардия артиллерия-миномет полкы командиры гвардия капитаны Шамил Рәхмәтуллин Алтын Йолдыз белән бүләкләнә. Шунысы гаҗәп: аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп тутырылган бүләкләү документын имзалаучы – янә бер милләттәшебез, 16 нчы гвардия кавалерия дивизиясенең артиллерия командующие (документта шулай язылган) гвардия подполковнигы Мансур Вәлиев. 10 октябрь көнне кул куелган документта полк командирының батырлыгы төгәл тасвирлана. 1943 елның 30 сентябрендә дошманның көчле артиллерия утына һәм һавадан бомбага тотуына карамастан, Белоруссиянең Гомель өлкәсенә керүче кала тибындагы Лоев бистәсе янында Рәхмәтуллин үз полкын Днепр елгасының көнбатыш ярына алып чыгуга ирешә. Әмма кечү дошман авиациясе тарафыннан җимерелү сәбәпле, дивизиянең кавалерия эскадроннары һәм пехота частьлары елга аша чыга алмый кала. Үзләре яулап алган плацдармны саклап калу өчен башланган тиңсез көрәш 36 сәгать дәвам итә. Рәхмәтуллин җитәкчелегендә артиллеристлар дошманның үзйөрешле туплар ярдәмендә танклар һәм пехота кулланып өзлексез дәвам иткән контратакаларын кире кага. Шуннан файдаланып, дивизия көчләре елганы кичеп өлгерә. Плацдармны саклап калу артиллеристларның фидакярлеге һәм командирның шәхсән батырлыгы исәбенә ирешелә. Дошманның көчле артиллерия утына һәм һавадан бомба яудырып торуына карамастан, ул үзенең күзәтү пунктын калдырмый, әмма үзйөрешле «Фердинанд» тубының төбәп аткан снаряды батырның гомерен өзә. Шул батырлыклары өчен гвардия капитаны Шамил Рәхмәтуллинны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итү 16 нчы гвардия кавалерия корпусы командиры гвардия полковнигы Григорий Белов һәм 7 нче гвардия кавалерия корпусы командиры гвардия генерал-майоры Михаил Константинов тарафыннан да яклау таба. 30 октябрьдә Үзәк фронтының артиллерия командующие генерал-полковник Василий Казаков тәкъдимне хуплый, 11 нче декабрьдә фронт командующие армия генералы Константин Рокоссовский белән хәрби совет әгъзасы генерал-лейтенант Константин Телегин үз ризалыкларын белдереп, имзаларын куя. Милләттәшебезне Алтын Йолдыз белән бүләкләү турында СССР Югары Советы Президиумы Указы чыккан көн – 1944 елның 9 марты. Чернигов паркындагы туганнар каберлегендә җирләнгән Советлар Союзы Герое, Ленин, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры гвардия капитаны Шамил Рәхмәтуллинның исеме Казан һәм Украинадагы шул кала урамнарына бирелгән.



119

Вх. №01412 23.10.43

74

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество РАХМАТУЛЛИН ШАМИЛЬ САИДОВИЧ.
2. Звание гвардии капитан 3. Должность, часть Командир – 146 – артиллерийского-минометного полка 14-ой кавалерийской дивизии 7-го гвардейского кавалерийского корпуса.
Представляется к присвоению звания ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА посмертно.
4. Год рождения 1920 г. 5. Национальность Татарин 6. Партийность канд. ВКП/б/1943 г.
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) Участник отечественной войны с 27.6.43 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне Ранен 31.12.42 г.
9. С какого времени в Красной Армии в РККА с 1939 г. 10. Каким РВК призван Кадровый РККА.
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Двумя орденами Красной Звезды и двумя орденами Отечественной войны 1-ой степени.

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

30 сентября 1943 г. 146 гвардейский артиллерийский минометный полк форсировал реку Днепр под сильным артиллерийским и минометным огнем противника. Разбитая авиацией противника переправа задерживала переход эскадронов дивизии и частей пехоты и артиллерийский минометный полк оказался один на небольшом участке западного берега р. ДНЕПР.

Заняв боевой порядок, гвардии капитан Рахматуллин организовал оборону и огнем артиллерии полка и личного оружия артиллеристов в течении 36 часов отражал массированные контратаки танков и пехоты противника, поддерживаемые огнем самоходных пушек пока не переправились конники дивизии и пехотные части.

Плацдарм на западном берегу реки ДНЕПР был удержан благодаря отваге и мужества артиллеристов и личному героизму гвардии капитана РАХМАТУЛЛИНА не покинувшего своего командного пункта несмотря на массированный огонь артиллерии противника и бомбежку с воздуха.

Прямым попаданием снаряда самоходной пушки "Фердинанд" в наблюдательный пункт, гвардии капитан РАХМАТУЛЛИН был убит.

Достоин присвоения звания ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА посмертно.

Командующий артиллерией 16 гв. кав. дивизии
гвардии подполковник /ВАЛИЕВ/

10 октября 1943 г.

Командир (начальник)

194 г.

* * *

Офицер-артиллерист Равил Рәхмәтуллин да яу кырында үзен аямыйча, батырларча сугыша. Аны беренче орденга Үзәк фронтның 2 нче танк армиясе составындагы 3 нче танк корпусының 728 нче аерым танкларны юк итү дивизионы командиры капитан Гуренко 1943 елның 2 сентябрендә тәкъдим итеп, бүләкләү документын имзалый. Батарея командиры лейтенант Равил Рәхмәтуллинның Кызыл Байрак орденына лаек булуын 3 нче танк корпусының артиллерия командующие подполковник Валнов та яклап үз имзасын куя. Әмма корпус командиры генерал-майор М.Д.Синенко алар белән килешми һәм 12 сентябрьдә батарея командирын I дәрәҗә Ватан сугышы орденына лаек дип кул куя. Максим Денисовичның корпус буенча үзенең 15 яугирен орденнар белән бүләкләү турындагы ышерен Боерыгы тагын биш көннән дөнья күрә, I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнүче 4 артиллеристның берсе – лейтенант Рәхмәтуллин. Мәрьям Дибаеваның 1944 елның 25 февралендә дөнья күргән мәкаләсендә өлкән лейтенант Равил Рәхмәтуллинның өч хәрби орден белән бүләкләнүе ташка басылган. Әлбәттә, бирелдә хата эзләү урынсыз. Беренчедән, сугыштан соң инженер-полковник званиесендә отставкага чыккан якташыбыз турында хәрби чыганакларда мәгълүмат бик аз, хәтта аның 1943 елның 1 июнендә Мәскәү хәрби округында оешкан, Курск-Орел орышында катнашкан, сентябрь аенда Ставка резервына чыгарылган һәм 1944 ел башыннан 2 нче Украина фронты гаскәрләрен көчәйткән 728 нче аерым танкларны юк итү дивизионында кайчанга кадәр хезмәт иткәнлеген ачыклау да мөмкин түгел. Һәрхәлдә, инженер-майор Равил Рәхмәтуллинның тагын 99 нчы зенит артиллериясе дивизионында, 443 нче һәм 88 нче запастагы зенит-артиллерия полкларында хезмәт итүе мәгълүм.

Сугышның башыннан ахырына кадәр хәрби авиациядә Казаннан тагын бер офицер – Шамил Рәхмәтуллинның катнашуы мәгълүм, әтисенең аты – Сәлим. Ул да беренче орденга, Равил Рәхмәтуллин шикелле, 1943 елның икенче яртысында лаек була. Үзенең штаб башлыгы гвардия майоры Шамил Рәхмәтуллинны хөкүмәт бүләге – Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим итеп, 26 июльдә тутырылган бүләкләү документын имзалаучы – 80 нче гвардия бомбага тоту авиациясе полкы командиры, гвардия подполковнигы Николай Рыбальченко.

(Дәвамы киләсе санда).

Рәис ЗАРИПОВ.

Хөсәен Фәезханов фидакярлеге

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

Кулъязмаларны 1986 елда Ш.Мәрҗанинең оныкчыгы Даниял, аларның төрле язмышка дучар булырга мөмкинлеген уйлап, төрле фондларга – университет китапханәсенә, бер өлешен Милли китапханәгә тапшырган. Университет китапханәсендә Х.Фәезхановның авылдашы, Сафаҗәй авылында мәдрәсә тоткан, анда укыткан Хәбибулла ишан Әлмөхәммәтовка язган хаты саклана. «Бу – бик мөһим хат. Аннан без тарихчы галимнең авылдашларына булган мөнәсәбәтен, Сафаҗайда нинди кешеләр яшәгәнен, аларның шөгыльләрен белә алабыз», – ди Фәнни китапханәнең директор урынбасары Эльмира Әмирханова.



Әдәбият галиме-текстолог, нәкышчы Нәҗип Нәккаш Хөсәен энесе Габделгалләмнең дә укымышлы, талантлы шәхес булуы турында ассызыклый. Ул татар әдәбияты өчен элеккеге Көнчыгыш әдипләре әсәрләрен татар теленә тәрҗемә иткән. «Тутыйнамә»се һиндлардан килә торган тутый кош әкиятләреннән алып язылган. Ибн эл-Мөкаффагның «Кәлилә вә Димнә» китабы – Шәрык әдәбиятының гүзәл үрнәкләренең берсе. Н.Нәккаш үзе – 2008 елда дөнья күргән «Кәлилә вә Димнә» китабын сәнгатьчә бизәүче автор һәм хәзерге әдәби телгә әзерләүче дә.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотолары.

Гаяз Исхакый һәм Габдрәшит Ибраһим мөнәсәбәтләре

(Ахыры. Башы 20-22 нче саннарда).

Моңа кадәр Г.Исхакыйның милли матбугат битләрендә Г.Ибраһимны даими тәнкыйтьләп торуын аларның сәяси карашлары төрле булуы белән аңлатырга тырыштык. Әмма Г.Исхакыйның сиксән яшенә җиткән милләттәшен Токио мәчетенә имам итеп куюга ни өчен шулай ябырылып каршы чыгуын, аны кылмаган гөнаһларда гаепләвен инде сәясәт белән генә аңлатып булмый. Монда инде сүз Исхакыйның холкы, бер дошманлашкан кешесен ахыргача дошман итүе турында бара, ул кеше аның милләттәше, дин кардәше булса да... Г.Ибраһимның артык мавыгучан холкы да кайвакыт аның үзен талатырга сәбәпче була, аның Япониядә мәчет салдырырга йөргән күпләр көлеп кенә кабул итә, моңа ышанмыйлар.



● Токиода 1938 елда ачылган Җәмигъ мәчет.

Әмма бу юлы да эшләр Г.Исхакый әйткәнчә булмый, 1938 елның 12 маенда Токиода яңа мәчет ачыла һәм аның имамы итеп Г.Ибраһим сайлана, ул шулай ук Япониянең мөфтие итеп тә билгеләнә. Шушы көнгә хәтле Токио мәчетен ачтыру артыннан йөргән, инде кунакларга чакыру билетларына кадәр тараткан Мөхәммәд-Габделхәй Корбангалиев 5 май көнне япон полициясе тарафыннан кулга алына. Әлбәттә, бу хәл Г.Исхакый аның өстеннән япон хөкүмәтенә язган өчен генә булмагандыр, шулай ук Г.Исхакый тарафдарларының аңа протест-бойкот белдерүләре дә артык зур роль уйнамагандыр. Японнар һәр нәрсәне уйлап эшли торган милләт, димәк, мәчет ачылыр алдыннан гына шул мәчетне төзетүче, аның имамы булырга тиешле кешене кулга алу бик җитди сәбәпләр аркасында гына була ала. 28 майда Г.Корбангалиевкә Япониядән чыгып китәргә тиешлеге турында документ тапшырыла, ул Маньчжуриягә сөрелә. Г.Корбангалиев аннан да, адвокат яллап, Токио мәчете өчен көрәшен карый, шул сәбәпле, Г.Ибраһим белән дә конфликтка керә. Әмма 1945 елда, совет гаскәрләре Маньчжуриягә кергәч, Корбангалиев кулга алына һәм конвой астында СССРга озатыла, 10 ел буе Владимир шәһәре төрмәсендә утыра, иреккә чыккач, туган яклары – Чиләбе өлкәсенә кайтып, имам була, 1972 елда шунда үлә (Али Мертхан Дюндар. Тюркские следы на японской земле. Культурное наследие: Тюркско-татарские мечети в Маньчжурии и Японии. – Анкара, 2008, стр.139.)

● **Токиода Җәмигъ мәчетнең ачылышы. Түрдә - милләттәшебез, мәчетнең беренче имамы Габдрәшит хәзрәт Ибраһим. 1938 ел, 12 май. Токио. Япония.**

Совет гаскәрләре Маньчжуриягә кергәч, Г.Исхакыйның да күп тарафдарларын кулга алалар, Россия төрмәләренә озаталар. Г.Ибраһим үлгәнче Токиода яши, милләтебезгә һәм динебезгә хезмәт итә, аның тырышлыгы белән, 1939 елда ислам дине Япониядә рәсми дин дип таныла, төрек-татар тарихы рәсми дәреслекләргә кертелә һәм укытыла башлый, 1939 елда Япониядә Беренче бөтендөнья мөселман конгрессы уздырыла, Габдрәшит хәзрәт аның түрендә була. Ул 1944 елның 31 августында 87 яшендә бакыйлыкка күчә, дәүләт дәрәҗәсендә җирләнә, кабере Токионың мөселман зиратында.

Исхакый да үлгәнче милләтебезгә хезмәт итә, берсеннән-берсе яхшы әсәрләр язып калдыра. Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, ул Польшадан Төркиягә күчә, сугыштан соң Япониядән Төркиягә күчеп кайткан татар мөһаҗирләренә зур ярдәм итә. Гаяз Исхакый 1954 елның 22 июлендә 76 яшендә бакыйлыкка күчә, кабере – Истанбулның Әдернәкапы зиратында, милләттәше, көрәштәше Йосыф Акчура белән янәшә.

Исхакый белән Г.Ибраһим икесе дә милләтебезгә хезмәт иткән, аның азатлыгы өчен көрәшкәннәр, зур иҗади мирас калдырганнар. Алар татарның бәйсезлегенә төрле юллар белән барган – Г.Исхакый кулында милли байрак, Габдрәшит хәзрәт кулында дини байрак булган, аларны, нигездә, сәяси карашлар гына аерган. Г.Ибраһим дөньякүләм дәрәҗәдә эшләгән һәм танылган, ә Г.Исхакый бөтен көчен үз милләтенә биргән. Алар бер изге максатка – татарның азатлык идеясенә эшләгән. Әмма Г.Ибраһим татар кысаларына гына сыймаган, ул, XX гасырның беренче яртысында, ислам лидеры буларак, геополитик дәрәҗәгә чыккан, дөньякүләм сәяси исламга нигез салган, Европа, Азия һәм Африка халыкларының ул чактагы милли тормышларын һәм тарихларын язып калдырган. Шуңа күрә аның хезмәтләрен бүген Төркиядә, Япония, Көньяк Корея, Кытай, Германия, Франция, Мисырда, гарәп илләрендә өйрәнәләр. Габдрәшит хәзрәт кая гына барса да, беренче урынга ислам динен һәм үз милләтен куйган, дөньяга татар халкының тарихын аңлаткан, милләтнең азатлыгы юлында аркадашлар эзләгән. Г.Исхакый милләтнең азатлыгын аның дәүләт бәйсезлегендә күргән, дөнья буйлап йөреп, халкын шуңа әзерләгән, әдәби, тарихи, публицистик әсәрләре аша татарның милли үзаңын уяткан. Бу ике шәхес безгә икесе дә кадерле, алар икесе дә милләт горурлыгы, аларның икесенең дә мирасы зур хөрмәткә лаек. Һәм аларның узган гасырдагы каршылыкларына дөрес бәя бирелсен, ул бүген алар дәвамчыларының дошманлыгына әйләнмәсен иде. Милләт мәсьәләсендә карашлар төрле булырга мөмкин, әмма беркем дә азатлык идеясенә хуҗа, монополист була алмый! Милләт өчен эшләгән һәр кешенең кадерен белергә кирәк, һәркемнең үз урыны, үз миссиясе бар. Һәм аны тәкъдир билгели... Тарих бәя бирә. Аллаһ хөкем итә.

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

СҮНМӘС ТАЛАНТ

Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин 1946 елның 6 гыйнварында Казан шәһәрендә дөньяга килә. Әтисе Шәкүр репрессияләнеп кулга алынганда, улы Рәшит бер яшь тә җиде айлык була. Әнисе Бәдерниса апа Рәшитне ялгыз үстерә. Булачак баянчы үсмер чакта әтисезлекнең, башкалардан читләштерелүнең газапларын татып үсә. Шулай да музыка мәктәбендә укый, аннан соң музыка училищесына керә. Әмма бер ел укыганнан соң, «әзерлексез» малайны училищедан чыгаралар. Ә Рәшит Ижау шәһәренә китеп укуын дәвам итә, училищены тәмамлап, ансамбльгә 1964 елны баянчы булып урнаша. Марс Макаров, Нәсыйх Вилданов, Илдар Җаббаров янына аны дүртенче баянчы итеп алалар. Ул елларда Рәшит, армиядә хезмәт итәргә теләк белдереп, ДОСААФның Казан аэроклубына керә. Очучылыкка укып, запастагы офицер буларак, Краснодар өлкәсендәге Ейск шәһәренә китеп бара, зур-зур самолетларда оча.

1968 елда Рәшит яңадан Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленә баянчы булып кайта. Ул вакытта ансамбльне композитор А.Ключарев җитәкли. Ул Мәдәният министрлыгыннан ансамбльгә 16 кешелек оркестр штаты өчен рөхсәт ала. Рәшит үзе әйтүенчә, ул заманда Идел төбәгендәге милли оркестрларда думбра, баян, балалайка өстенлек итәргә тиешлеге турында күрсәтмә була. А.Ключарев исә оркестрга скрипка, флейта, кларнет кертә. Ул үзе атаклы гармунчы Фәйзулла Туишевка да аккомпаниатор булган музыкант. Ә Фәйзи Биккинин, Гали Җәмлиханов кебек мәшһүрләргә аккомпаниатор булу бәхете инде Рәшиткә елмая. Ф.Биккининның вафатыннан соң Рәшит аның атаклы гармунын сатып алып кына калмый, ә бәлки, халкыбызның бу тиңсез талантлары моңын сүндермичә, ялгап алып та китә. А.Ключаревның милли оркестр турындагы хыялын да ул күңеленә сеңдереп кала, шушы эшкә йөрәк көчен сала.

Күпме гомер ансамбльдә эшләү – ул яңа сынаулар да, яңа табышлар да, осталык үрләренә менү баскычлары һәм тормыш университетлары да. Бу чорда ансамбльдә бик күп җитәкчеләр алышынды. Рәшитне төрле урыннарга эшкә чакырсалар да, ул ансамбльдә калды. Юк-бар хезмәт хакына сәнгатькә хезмәт итте. Гастрольләр вакытында тимер юл вагоннарында яшәп көн күрде, әмма ансамбльгә барыбер тугры калды.

Ансамбльнең үз оркестрын 1960-1961 елларда – Җ.Айдаров җитәкчелек иткән чорда – Кытайга бару өчен оештыралар. 1968 елда янә оркестр төзеп, аны А.Ключарев Мәскәүгә алып бара… Соңрак, югары музыкаль белем алгач,бу эшкә, җиң сызганып, Рәшит тотына. Ул үзе оркестрның туган елы дип 1972 елны саный. Ә 1996 елда, ниһаять, оркестр тулы составы белән Франциягә бара. Коллективка белемле, талантлы музыкантлар туплана.

Үзе ундүрт төрле уен коралын «иярләгән» Р.Мостафин үз оркестрындагы һәр музыкант берничә уен коралында уйный алырга, ким дигәндә ике-өч инструментны үзләштерергә тиеш, дип саный.

Р.Мостафин – республиканың әйдәп баручы баянчы-башкаручысы да. Югары һөнәрмәндлек, иҗат фантазиясе һәм чикләнмәгән импровизация Р.Мостафинга халык музыкасын иң яхшы башкаручыларның берсе булырга ярдәм итте. Без аны композитор һәм аранжировкачы буларак та беләбез. Ул язган көйләр халыкчанлыгы, кабатланмас булуы белән сокландыра. Рәшитнең табигать тарафыннан бирелгән талантын үстерүгә аның укытучылары – бөек музыкантлар, композиторлар һәм дирижерлар булышты. Күп еллар буена Җ.Айдаров, Җ.Котдусов, Х.Фазлуллин, З.Хәбибуллин, Ф.Әхмәтов, Г.Ротт, И.Шакировлар белән тыгыз иҗади элемтәдә булды. Р.Мостафинның музыкант булып җитлегүенә композитор А.Ключарев аеруча зур йогынты ясады. Ул аңардан композиция һәм оркестровканы өйрәнде. Ансамбльгә нигез салучыларның берсе А.Ключарев Р.Мостафинда үзенең фикердәшен һәм дәвамчысын күрде. Ансамбльнең үз оркестрын булдыру Ключаревның иң зур хыялы була, һәм остазының хыялын Мостафин тормышка ашыра алды. Ул татар көйләрен генә түгел, башка халыклар музыкасын да башкарырга сәләтле оркестр барлыкка китерде. Мәсәлән: татар, мари, башкорт, чуаш, азәрбайҗан, үзбәк, каракалпак, кыргыз, казах һәм башка халыклар фольклоры нигезендә эшләнгән «Төрки дөнья» программасында да оркестрның роле гаять зур. Әйтергә кирәк, башка халыкларның көен оркестр музыкантлары шул милләтнең үз уен коралында башкара. Бу музыка оркестр өчен Р.Мостафин тарафыннан искиткеч камил эшләнгән. Аңа инструментларның һәм аранжировкаларның тиңе яки бу халыкка гына хас яңгырашын бирүдә югары профессиональлек хас.

Казан татарларының шәһәр фольклорына нигезләнгән «Шәрык клубы» программасының идеясен ансамбльнең сәнгать җитәкчелегенә Р.Мостафин тәкъдим итә. Оркестр өчен бөтен музыка Р.Мостафин тарафыннан языла һәм оркестр өчен эшкәртелә.

Казан студиясендә «Татар гармуннары» дигән фильм төшерелә һәм анда биш төрле гармун, курай һәм кубызда Р.Мостафин башкарган көйләр языла. Мәскәүдә үткәрелгән Татарстан мәдәнияте көннәрендә Р.Мостафин В.Дерингның кинематография джаз оркестры белән татар темаларына фантазия башкара. «Мелодия» фирмасы оркестр белән хор һәм оркестрның соло язмалары пластинкаларын чыгара.

Оркестр җитәкчесе Россиянең татарлар күпләп яшәгән өлкәләре – Оренбург, Бондюг, Әстерхан, Кырым, Себер, Касыйм татарларының бай фольклор материалларын оста куллана.

Р.Мостафин оригиналь музыка да яза. Күп биюләр, мәсәлән, «Казан кызлары биюе», «Канатлы яшьлек», «Биш пар», «Авыл биюләре» («Әрни әле, әрни ул яра» программасыннан) һәм «Туй» биюләре һ.б. авторы булып тора.

Р.Мостафин оркестры аерым концертлар белән Франциядә (Мартиг-Прованс), Төркиядә (Истанбул) чыгыш ясый. Шотландиянең Абердин шәһәрендә, АКШ, Франция, Англия илләренең гимннары белән беррәттән, Р.Мостафинның оркестры Татарстан Республикасының гимнын беренче тапкыр чит илдә яңгыратты. Шулай ук Франциянең Конфолан шәһәрендә үткәрелгән бөтендөнья фестивален ябу Татарстан ансамбле оркестрына йөкләтелә. Мостафин Коста-Рика, Мексика, Испания, Франциядән дүрт оркестрны кушып, фестивальне тәмамлау церемониясен искиткеч оста башкарып чыга.

Ансамбльнең һәр уңышында, оркестрның, баш дирижерның кабатланмас өлеше бар. Осталарның остасы, остазларның остазы булган Р.Мостафинның югары профессиональлеге,таланты вакытында тиешенчә бәяләндеме соң? Хөкүмәтебез аңа лаеклы исем-бүләкләрне бирдеме? СССР заманында ук «СССРның халык артисты» исеме өчен әзерләнгән документлары берничә ел буена җитәкченең өстәл тартмасында ятканы билгеле. Тукай премиясенә дә ул күптән лаек иде.

Әйе, үзенә тәгаенләнгән юлны тапкан Талант йөрәгенең бөтен көчен халкына багышлый. 11 июнь көнне бакыйлыкка күчкән Рәшит Мостафин мәңге шушы хакыйкатьне үз иҗаты, үз язмышы белән раслап яшәде.

Филүсә АРСЛАН.

Лима Кустабаева: ***«Рәшит Мостафин – ансамбльгә гаҗәп дәрәҗәдә бирелгән кеше. Төрле авырлыклар да, «төшемле» эш белән кызыктырулар да аны ансамбльдән аера алмады. Кешенең үз эшен, үз коллективын ярата белүе – бик тә мөһим сыйфат ул. Рәшит – югары профессиональ дәрәҗәдәге музыкант, башкаручы, оста аранжировкачы, милли уен коралларының мөмкинлекләрен тулы камиллектә белүче».***

Айрат Хәмитов, Татарстанның халык артисты, ансамбльнең сәнгать җитәкчесе: ***«Рәшит Шәкүр улы өчен иң мөһиме – милли сәнгатебездә алгарыш булуы. Ул бөтен музыкаль байлыкны да башкарырга сәләтле музыкант. Шунысы сөенечле – республикада аның коллективыннан үрнәк алып күпме коллектив туды. Р.Мостафин җитәкчелегендәге оркестр маяк булып, алдан әйдәп баручы коллектив ул».***

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

17 июнь (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 21.28 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.32 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Эремчек суы (1)

Көн саен иртән 1 чынаяк эремчек суы эчсәң, иммунитетны тиз арада ныгытып була. Әлеге судагы лактоза шикәре эчәклектә бик әкрен генә сеңә, бу исә әчү һәм газ барлыкка килү процессларын әкренәйтә, 2-3 атна эчендә эчәклек микрофлорасы эшчәнлеген җайга сала. Эремчек суы калийга да бай. Ул организмнан артык сыеклыкны, аның белән бергә токсин-шлакларны, зыянлы холестеринны да чыгара. Әгәр организмга көн саен 30 грамм гына булса да эремчек суы керсә, стресс гормоннары эшләп чыгару туктала, ә шатлык гормоны серотонин эшләнү арта. Эремчек суы ашыйсы килүне бетерә, В витамины күп булганга, май һәм углевод алмашын активлаштыра.

18 июнь (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 3.11 сәгатьтә калка, 22.33 сәгатьтә бата. 7 сәгать 37 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

Эремчек суы (2)

Эремчек суын өйдә ясау бер дә кыен түгел. Сөтне җылы урынга куеп әчетәләр, аннан соң ут өстендә кайнатып чыгара язып сүндерәләр. Суынгач, сөзәләр. Суын эчәргә, эремчеген ашарга ярый. Яисә кайнап чыга язган 2 литр сөткә 1 лимон согы кушалар, яхшылап болгаталар һәм уттан алалар. Сөт эремчек һәм суга бүленәчәк, ярты сәгатьтән соң берничә марля аша сөзәргә генә кирәк (500 грамм эремчек һәм 1,5 литр эремчек суы барлыкка килә). 100 грамм теләсә нинди җиләкне изеп, 1 әр аш кашыгы шикәр һәм лимон согы, тәменчә дарчин, 250 грамм эремчек суы кушалар – сихәтле коктейль әзер!

19 июнь (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 3.59 сәгатьтә калка, 23.16 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашыгача талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

20 июнь (сишәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

йолдызлыгында,5.02 сәгатьтә калка, 23.44 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Йөзем шифасы

Әгәр төнлә аякны көзән җыерса, болай дәваланалар. Кичтән 2 аш кашыгы йөземне 1 л кайнаган суга салып калдыралар. Икенче көнне йөзем суын чәй урынына (3-4 тапкырга бүлеп) эчеп бетерәләр, җимешләрен ашыйлар. Кичтән яңа төнәтмә ясап калдыралар, 2 атна буе шулай дәваланалар. Кабыгы белән пешерелгән бәрәңге, банан, хөрмә, алма ашау да тамыр тартышуын киметә.

21 июнь (чәршәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 6.16 сәгатьтә калка,0.02 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, кумәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Зобтан дәва

Калкансыман биз зурайганда, атнасына бер тапкыр болай дәвалану яхшы. 1 әр стакан әстерхан чикләвеге, карабодай балы, карабодай онын кушып, әйбәтләп болгаталар, бишкә бүләләр һәм көн буена ашап бетерәләр. Башка бернәрсә дә ашарга ярамый, эчәргә генә ярый.

22 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 7.34 сәгатьтә калка, 0.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Куңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланыуын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Дәфнә мае

15 данә дәфнә (лавр) яфрагын ваклап, банкага тутыралар, өстенә ярты стакан көнбагыш мае салып, караңгы җылы урында 10 көн төнәтәләр, сөзеп, суыткычта саклыйлар. Артрит, ревматизм, миозит, радикулит интектергәндә, шулай ук инсульттан соң хәрәкәтләнүне торгызу максатында төнгелеккә дәфнә мае сөртеп дәваланалар.

23 июнь (җомга). ***Зөлхиҗҗә аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,8.53 сәгатьтә калка,0.21 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә эти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Безләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Сыр шарчыклары

400 г сыр, 1 йомырка, 3 аш кашыгы он, 2 аш кашыгы атланмай кирәк. Сырны вак угычта уалар, йомырка һәм йомшартылган май кушып, шарчыклар ясыйлар да, онда әвәләп, майда йөздереп кыздыралар.

Хәзрәти Йосыф һәм төшләр хикмәте

«Йосыф» сүрәсенең 4 нче аятендә болай диелә:

«Менә (бервакыт) Йосыф атасына әйтте: «И, әтием! Һичшиксез, мин төшемдә унбер йолдыз, кояшны һәм айны күрдем. Аларны миңа сәҗдә кылган хәлдә күрдем».

Йосыф галәйһис-сәлам төшендә күргән унбер йолдыз – туганнарын; кояш – атасы Ягъкуб галәйһис-сәламне, ә ай исә анасының апасы Ләйаны белдерә. Чөнки әнисе Рахил инде вафат була.

Йосыф галәйһис-сәламнең туганнарын йолдыз рәвешендә күрүендә хикмәт туганлыкка кеше тормышының барышына юнәлеш бирә торган мөһим факторлар салынудан гыйбарәт. Кояш һәм айның йолдызлардан соң телгә алынуы исә Йосыф галәйһис-сәламнең атасы һәм түтәсе белән туганнарыннан соңрак очрашачагына ишарәли.

Йосыф галәйһис-сәлам бу төшне җиде яшендә күрә.

Бер яһүди Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килә дә: «Йә, Мөхәммәд! Йосыфның нинди йолдызларны күргәнлеге турында миңа хәбәр бир» – дип, сорау белән мөрәҗәгать итә.

Рәсүлуллаһ бер мизгелгә тынып кала. Җәбраил галәйһис-сәлам килеп, аңа йолдызларның исемнәрен белдерә. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм, яһүдигә борылып: «Әгәр сиңа бу хакта сөйләсәм, мөселман булырсыңмы?» – дип дәшә. Яһүди: «Әйе», – ди. Шуннан соң Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Болар – Җәрәйан, Тарыйк, Зәййал, Кабис, Амудан, Фәлик, Мысбах, Дарух, Фәраэ, Вәсаб, Залкәфитәйн. Йосыф төшендә менә шушы йолдызларның, кояшның һәм айның, күктән төшеп, үзенә сәҗдә кылганнарын күрде», – дип сөйләп бирә.

Шулчак яһүди: «Валлаһи, син сөйләгән исемнәр дөрестер!» – дип раслый.

Төшләр өч төрле була:

1. Җан-нәфес вакыйгалары. Кеше төшендә үз эш-гамәлләрен һәм иҗатын күрә, яки гашыйк зат сөйгәнен күрә. Болар – кеше тормышының бер нәтиҗәсе.

2. Шайтанның куркытуы. Җанны борчуга салган буталчык эчтәлекле төшләр турында сүз бара. Аларның мәгънәсе юк.

3. Аллаһтан килә торган хәбәрләр. Төш фәрештәсе кешегә Өммел-Китаптан бер нөсхә алып килеп, ләүхелмәхфуздә язылганнарны күрсәтер. Бу – чын төш, андыйларны «дөрес, садыйк төш» дип атыйлар. Болардан кала башка төшләр исә буталчык, аңлаешсыз була.

Дөрес төшләрне ләүхелмәхфуздән киләчәкне чагылдырган нур сызыгы дип атарга мөмкин.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Вакыты якынайган саен (Хәдис шәрехләүчеләр «вакыты якынаю» сүзтезмәсен «кыяматкә якын» яки «иртәнгә якын» (сәхәр вакыты) дип аңлата), мөэминнең төше беркайчан да диярлек ялган булмас (үзе күргәнчә чынга ашыр). Мөэминнең (тугры) төше пәйгамбәрлекнең кырык алты җузеннән берсе санала. Пәйгамбәрлектән килгән бернәрсә дә ялган булмас» (Бохари, «Тәгъбир», 26; Мөслим, «Рүя», 6).

Аяти-кәримәләрдә болай дип әйтелә: «(Атасы Ягъкуб галәйһис-сәлам) әйтте: «И, улым! Төшеңне абыйларыңа сөйли күрмә, юкса алар (көнчелекләре аркасында) сиңа тозак корырга уйларлар. Һичшиксез, шайтан – кешеләргә ап-ачык бер дошман. Болай булгач (төшеңдә күргәнчә), Раббың сине сайлаячак, сиңа (төшеңдә күргән) хәбәрләрнең мәгънәләрен юрауны өйрәтәчәк, сиңа да, Ягъкуб нәселенә дә, бабайларың Ибраһим һәм Исхакка биргән кебек, нигъмәтен бирәчәк. Һичшиксез, синең Раббың – (һәрнәрсәне) Белүче, Хикмәт иясе» («Йосыф», 5-6).

Йосыф галәйһис-сәлам уянып, төшен атасына сөйләгәч, атасы аның дөньялыкта һәм бакыйлыкта бик зур хөрмәткә һәм югары дәрәҗәгә ирешәчәген аңлап ала. Ул баласына төшен сер итеп сакларга, туганнарына сөйләмәскә куша. Югыйсә туганнары аңа, көнләшеп, хәйлә, тозак корырга мөмкин икәнлеге турында әйтеп куя. Димәк, хөсетлектән генә түгел, хөсетлек корбаны булудан да саклану таләп ителә.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу мәсьәләдә болай дип кисәткән: «Ихтыяҗларыгызны канәгатьләндергәндә яшеренлекне кулланыгыз, чөнки һәр нигъмәт иясеннән көнләшерләр» (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр»).

Дарван кыйссасы

Риваятькә күрә, юмарт бер йәмәнленең Сана тирәсендә йөзем, хөрмә һәм иген бакчасы була. Бу юмарт кеше уңыш җыйган вакытларда фәкыйрьләргә, мөһаҗирләргә һәм зәгыйфьләргә гошер өлешен мулдан аера, арттырып бирә. Үлем сәгате якынайгач, улларын җыеп, бу эшне дәвам итәргә васыять әйтә. Ләкин әлеге изге зат вафат булгач, балаларының күзен малга хирыслык томалый, алар үз араларында: «Гаиләбез бик зур, кеше күп, мал исә аз. Хәзер инде фәкыйрьләргә бернәрсә дә бирмик! Алар килеп сораганчы, уңышны җыеп алыйк...» – дип вәгъдәләшәләр.

Аллаһ Тәгалә аларның мондый яман ниятләренә каршы, бакчаларын яндырып, кап-кара хәрабә хәленә калдыра. Ул зур бакча һич танымаслык рәвешкә керә. Бу хәлне күргәч, саран балалар: «Әллә ялгыш урынга килдекме?» – дип аптыраштa кала.

Югыйсә аталарының гошерне юмарт өләшеп, мохтаҗларның догасын алуы бакчага бәрәкәтне артыгы белән биреп тора. Барлык фәкыйрьләр һәм мөһаҗирләр шул бакчадан файда күрәләр. Тик аталары ярлыларга тараткан гошер балаларының күзенә зур булып күренә һәм аны һич бирергә теләмиләр. Алар Аллаһ ул бакчага биргән бәрәкәтнең каян килгәнен белмиләр-аңламыйлар, чөнки гафләт аларның йөрәкләрен сукырайткан була. Шуңа күрә дә Җәнабел-Хак: «Гафилләрдән булма!» дип кисәтә («әл-Әгъраф», 205).

«Дарван әһелләре» кыйссасы дип танылган бу вакыйга Коръәни Кәримдә түбәндәгечә бәян кылына: «Һичшиксез, Без (үз вакытында) бакча ияләрен сынаганыбыз кебек, аларны да (Аллаһ Рәсүленә каршы чыккан мөшрикләрне) сынадык. Менә алар (бакча ияләре) иртә җитүгә, (һичкемгә күренмичә) тулысынча аны (уңышларын) җыеп алачакларына ант иттеләр. Алар өстәп (искәрмә дә) әйтмәделәр («Иншә Аллаһ» дип әйтмиләр һәм фәкыйрьләрнең өлешен аермыйлар). Алар йоклаган вакытта Раббыңнан (җибәрелгән) уратып ала торган бер бәла аны йөреп чыкты. Иртән кисеп ташланган кебек булды. (Бу тарафта исә) алар иртән бер-берсенә дәштеләр. «Бакчагызга барыгыз, әгәр уңыш җыярга җыенган кешеләр булсагыз». Алар, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, анда кузгалдылар. «Бүген (анда) бер генә фәкыйрь дә сезгә (арабызга) кермәсен». (Әйе, ярлыларга ярдәм итәргә хәлләре җиткән килеш, аларны ярдәмнән мәхрүм итү нияте белән) көчле икәнлекләрен санап, иртән юлга чыктылар» («әл-Каләм», 17-25).

Бакчаларына барып җитеп, саранлыкларының һәм хәйләкәрлекләренең авыр нәтиҗәсен күргәч, үкенеч утында яналар. Җәнабел-Хак аларның аптыраштa калуын һәм үкенечләрен болай тасвирлый: «Әмма аны күргәч, әйттеләр: «Без юлдан язганбыз. (Ялгыш җиргә килмәгәнлекләрен аңлагач) Юк! Без мәхрүм ителдек!» Араларындагы иң уртачалары (инсафлылары): «Мин сезгә (Аллаһны) тәсбих итәргә кирәк», – димәгән идемме?» – диде. Алар: «Аллаһ пакь! (дип Раббыбызны тәсбих итәбез). Һичшиксез, без (үз-үзебезгә) золым эшләдек», – диделәр. Алар бер-берсен шелтәли башладылар. (Ахырда) әйттеләр: «Ни үкенеч безгә! Без чиктән ашкан кешеләр булдык. Бәлки, Раббыбыз безгә моның урынына моннан да яхшырагын бирер. Һичшиксез, без (инде) Раббыбызга кайтабыз (Аның ризалыгын телибез)» («әл-Каләм», 26-32).

Әлеге аятьләрдә ярлы-ябагайга, йортсыз-җирсезгә гошер өлешен бирмәс өчен хәйләгә барган мәрхәмәтсез бакча хуҗаларының кайгылы язмышын Җәнабел-Хак, бер гыйбрәт итеп, шундый күркәм рәвештә белдерә. Йөрәкләрдәге барлык ниятләр дә Җәнабел-Хакка билгеле. Аның кодрәте, бөеклеге һәрнәрсәне колачлый.

Аллаһ Тәгалә бу кыйссаны менә шушы мөһим кисәтү белән тәмамлый: «Газап шундый. Ахирәт газабы исә моннан да зуррак. Әгәр белсәләр иде!» («әл-Каләм», 33).

Туган якның тиңсез таланты

Лениногорск шәһәрендә эшләп килгән Ш.Бикчурин исемендәге «Чишмә» иҗат берләшмәсе әгъзалары әлеге әдәби берләшмәне 25 ел җитәкләгән музыкант, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, Р.Төхфәтуллин, С.Сөләйманова исемендәге премияләр лауреаты, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, ун ел Әлмәт Язучылар берлеген җитәкләгән, дистәләрчә шагыйрь-язучының китапларын дөньяга чыгарган шәхес – Разим Вәлиуллинның туган ягында искә алу кичәсендә катнаштылар.

Зәй районының Кәдек авылына Лениногорскидан килгән кунакларны җылы каршы алды алар. «Чишмә»леләр иң элек шагыйрьнең туып-үскән нигезендә булды. Ул яшәгән йорт күңелдә моңсу хисләр уята. Бу нигездә беркемнең дә яшәмәвендә авыл язмышына тәңгәллек сиземләнә. Хәзерге көндә Разим Вәлиуллинның туган авылы Кәдектә кырык өч йорт булып, барысы биш йортта гына тормыш барлыгы сизелә. Димәк, авылның киләчәге куандырмый дигән сүз.

Килүебезнең төп максатларыннан берсе Разим абыйның әнисе, туганнары һәм үзе җирләнгән зиратта авыл имамы белән берлектә аларның рухына дога кылу иде.

Лениногорск делегациясе Р.Вәлиуллинның Сармашбаш авылы мәктәбендә урнашкан музеен карады. Мирасханәдә остазыбызның туганнан алып соңгы көненә кадәр гомере күз алдына килә. Кызганыч, Сармашбаш мәктәбендә нибары бер укучы барлыгы безне бик борчыды.

Сармашбаш мәктәбендәге музей мәктәп белән бергә ябылырга тиеш түгел! 2023 ел – Милли мәдәниятләр һәр гореф-гадәтләр елы. Шуны исәпкә алып, бар гомерен милләткә багышлаган шәхес музеен җуймаска, югалтмаска иде! Баласыз мәктәп ябылу белән талантлы шәхесебез Разим Вәлиуллинның тиңсез мирасының киләчәге булырмы?! Безнең фикеребезчә, әлеге мәдәни хәзинә сакланырга, татарга бүген дә, иртәгә дә хезмәт итәргә тиеш. Шул нисбәттән Разим Вәлиуллинның бертуган сеңлесе Кадрия ханымга, аның фикердәшләренә бүгенгә кадәр биниһая байлыкны күз карасыдай саклаганнары өчен йөрәк түреннән чыккан тирән рәхмәтләрне җиткерәсе килә!

Разим абыйның якты рухына багышланган искә алу кичәсе заманча бизәлгән мәдәният йортында узды. Без үзебезчә әдәби-музыкаль күчтәнәчләр әзерләп килгән идек. Билгеле, иң беренче нәүбәттә, залдагы халыкка остазыбызның халыкчан шигырьләрен, аның халык күңелендә сакланган, бүген дә яратып башкарыла торган җырларын ирештердек.

Әлеге мәртәбәле кичәдә шагыйрьнең иҗади дуслары, каләмдәшләре, шәкертләре, аерым алганда, Разим Вәлиуллин белән бергә укыган, аның белән озак еллар туган ягыбызга хезмәт иткән баянчы, фикердәше, якын дусты, музыкант, композитор Фәйзи Хөснуллин, аның иҗади шәкерте, каләмдәше, дусты, «Чишмә» иҗат берләшмәсе җитәкчесе, Ш.Бикчурин, С.Сөләйманова исемендәге премияләр лауреаты, шагыйрь, Мөэмин-Каратай авылы китапханәчесе Таһир Шәмсуаров, Разим Нәгыйм улының шәкерте, шагыйрә, музыкант, композитор, җырчы, Ш.Бикчурин исемендәге премия лауреаты Гөләндәм Кәбирова, Ш.Бикчурин исемендәге премия лауреаты шагыйрә Әлфия Сөләйманова, шагыйрә Илсөяр Салахова, Лениногорск шәһәренең 11нче гимназиясе укытучылары, «Айсылу» балалар театры җитәкчесе, режиссер, Ш.Бикчурин исемендәге премия лауреаты Зөмәрә Шәрәпова, педагог, шагыйрә Фәридә Әхмәтшина һ.б. катнашты. Әдәбиятка, мәдәнияткә гашыйк халык һәр чыгышыбызны алкышлап каршы алды.

Әлбәттә, әлеге очрашуның иң хөрмәтле кешесе – Разим Вәлиуллинның сеңлесе Кадрия Нәгыйм кызы иде. Разим абый сыман, ул да талантка, моңлы тавышка ия җырчы да икән әле! Кичә истәлеге буларак, Лениногорскидан килгән кунакларга Разим Вәлиуллин китаплары тапшырылды.

Таһир ШӘМСУАРОВ.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

16 июнь – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
17 июнь – Шәрык клубында 15.00 – «Артист» спектакле (Г.Кариев) һәм экскурсия. 18.00 – «Күзгә кайтаваз» (Р.Галиуллин).
18 июнь – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
20 июнь – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
21 июнь – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
22 июнь – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
23 июнь – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

16 июнь – Казан хореография училищесы укучылары концерты.
19 июнь – «Дама с камелиями» (Дж.Верди).
22 июнь – «Җәлил» (Н.Җиһанов).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

16 июнь – «Кияүләр» (Х.Вахит).
18 июнь – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
20 июнь – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
21 июнь – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
22 июнь – 10.00 – «Тинчуринда кунакта» квесты. 18.30 – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
23 июнь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре. Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

16 июнь – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
17 июнь – 13.00 – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.00 – «Җырлап ящик!» (Р.Латыйпов).
18 июнь – 13.00 – «Әлифба» (Л.Әхмәтҗанова, Э.Яруллина, Ф.Насыйбуллин).18.00 – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

16 июнь – Зур залда – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов). Кече залда – «Авиатор» (Е.Водолазкин).
17 июнь – Зур залда – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе). Кече залда – «Авиатор» (Е.Водолазкин).
18 июнь – фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Муха-Цокотуха» (К.Чуковский). Кече залда – «Өрә белмәгән көчек» (Р.Мөхәммәтша).
20 июнь – 15.00 – театр бинасы буйлап сәяхәт. Зур залда – «Shurale: яңа фантазия» (Ф.Яруллин). Кече залда – «Я люблю Вас, Надя!» (А.Чехов).
21 июнь – Зур залда – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әкияте, Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «Коза и Овца» (Г.Тукай әсәре, Г.Рәхим инсценировкасы) (спектакль рус телендә бара).
22 июнь – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әкияте, Л.Кожевников инсценировкасы).
23 июнь – 11.00 – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әкияте, Л.Кожевников инсценировкасы). Зур залда 18.30 – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь). Кече залда 19.00 – «Макбет» (У.Шекспир).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

20 июнь – «Губернаторский» Ульяновск дәүләт академия симфоник оркестры концерты.
21 июнь – «Кино» төркеменең танылган җырларын «Черный квадрат» төркеме башкара.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

18 июнь – мультконцерт.
23 июнь – танылган җырчы Ф.Шаляпинның 150 еллыгы уңаеннан «Душа и Родина» дип исемләнгән хор музыкасы фестивале.

Тарих кабатлана

Без хәзер түләүле белем алудан зарланабыз, ә бит уку өчен түләү Советлар Берлегендә үк кертелгән булган. 1940 елда Мәскәү һәм Ленинградта, шулай ук союздаш республикалар башкалаларында 8-10 нчы сыйныфларда уку өчен елына 200 сум, башка шәһәр һәм авылларда 150 сум түләгәннәр. Институтта укыган өчен дә 300-400 сум таләп ителгән. Күп гаилә өчен шулкадәр акча бик зур сумма булып, үсмерләр 7 нче сыйныфтан соң һөнәр училищеларына юл тоткан – илгә исә нәкъ шул кирәк булган, эшче куллар җитешмәгән. Нәтиҗәдә урта мәктәп һәм югары уку йортларын тәмамлаучылар саны ике тапкырга кимегән. СССРда түләүле белем бирү 1954 елда гына туктатылган.

(“АиФ”).

Тере “посылка”

1913 елның 1 гыйнварыннан АКШ Почта хезмәте хатлар гына түгел, авырлыгы 5 килограммга кадәр булган посылкалар да кабул итә башлый. Хәтта җан ияләрен җибәрү дә рөхсәт ителә. Әлбәттә, әлеге кararны чыгаручылар тавык, мәче, умарта кортларын күз алдында тота. Әмма норма тиешенчә аңлатылмый, шунлыктан кешеләр ... балаларын да почта аша җибәрә башлый. Чөнки сабыйның киеменә ябыштырыла торган почта маркасы поезд билетыннан шактый арзангарак төшә: 15-29 цент түлисең дә, тере “посылка” инде әби-бабасы янына барып та җитә. Иң беренче шундый очрак гыйнварда ук теркәлә. Батавия шәһәрчегендә хат ташучы, сигез айлык нарасыйны әти-әнисе өеннән алып, чакрым ярым арада яшәгән әбисенә илтеп бирә. “Посылка” әле 50 долларга иминиятләштерелгән дә була. Ничек инде сабыйны ниндидер хат ташучыга биреп җибәрсеннәр, дисезме? Тик ул вакытта кечкенә шәһәрләрдә хат ташучыны бөтен кеше таный торган булган, аңа ышанганнар, аның белән дуслашканнар. Һәм сабыйны, әлбәттә инде, баштарак белгән кешегә генә ышанып биреп җибәргәннәр. Бу турыда газеталар яза башлагач, идея кисәк популярлашкан. А пунктыннан Б пунктына җәяү һәм поездда бала җибәрүнең берничә очрагы теркәлгән. 1914 елның февралендә дүрт яшьлек Мэй Пьерсторфны поезд белән хәтта икенче штатка җибәрәләр, ул вакытка посылканың авырлыгын 20 килограммга кадәр җиткезү рөхсәт ителә. Пальтосына маркалар ябыштырылган кыз 120 чакрым үтә. Дөрес, хат ташучы аның туганнан-туган абыйсы була... Саран ата-аналарның баланы шулай җибәрү очраклары арта башлагач, кагыйдәләргә төзәтмә кертелә һәм 1920 елдан сабыйларны почта аша җибәрү тыела.

(“The Mirror”).

Логопед кошлар

Америкалы Брайан Уилсон янгын сүндерүче булып эшләгән, һәлакәткә очрап, башы җәрәхәтләнгән. Фаҗигадән соң ир-атның уң ягын паралич суккан, сөйләме аңлашылмый башлаган. Табибләр аны караваттан тора алмас инде, дип уйлаган. Өенә кайткач, тутый кошлары хуҗаларын бик сөенеп каршылыган, аның белән бертуктамый “сөйләшкән”. Сәгатьләр буе кошларын тыңлап утыргач, Брайан башта 1-2, аннан соң күбрәк сүзне кабат әйтергә өйрәнгән. Хәзер исә аның сөйләме тулысынча торгызылган, кайчандыр бөтенләй сөйләшмәгән дип әйтеп тә булмый.

(“Лента.ру”).

Кая да ярый

Немец табибләре ачыклаганча, энә кадап дәвалану кайвакыт баш авыртуын чыннан да баса ала, тик энәләрне акупунктурадагы кебек билгеле бер нокталарга гына түгел, теләсә кайсы җиргә кадау да булыша икән. Медиклар 270 кешене баш өянәгеннән дәвалаган: энәне кайберләренең тәнендәге традицион акупунктура нокталарына, кайберләренең очраклы урыннарына кадаганнар. Ике ысул да бердәй нәтиҗәле булып чыккан – ике төркемдә дә бер үк сандагы пациентларның баш авыртуы үткән.

(“Die Presse”).

Симерү сәбәбе

